During this period, some works of Musa Zharullah Bigiev were prohibited and Mahmoud Esad Effendi was asked a question about his view about this issue[5]. To this question Mahmoud Esad Effendi replied: "In every corner of the Islamic world we can meet ishmies. I am glad that his books were in Arabic, because Tatars, who do not speak Arabic, will escape being poisoned by reading his harmful books. As Mahmoud Esad Effendi wrote in the newspaper *Wakit*: "…Musa's book was popular with people. Everyone rushed to buy it, and I was one of them" [35: 2].

When asked to share the impressions he had experienced during his travel to the places the North Turkic people lived, Mahmoud Esad Effendi said: "Well, I was very glad. I was glad to see development and progress in the life the Northern Turkic people [6: 2-3]. In almost all big cities of Russia railway station kiosks are in the hands of Kasiym Tatars, in all the cities I went to, there are a lot of Tatar traders and shopkeepers. In Orenburg, Samara, Ufa and Kazan I met with Islamic community leaders engaged in religion, economy and business. Islam leaders shed the light of education from Kazan to China. Everywhere you can meet scientists, educators and merchants from Kazan and its countryside. Everywhere people have the greatest desire and diligence to progress. Kazan and its countryside are the Islamic world center that has made the most progress. Unfortunately, we do not realize the significance of it all. The Northern Turkic people do better in trade and craft than the Southern Turks. In particular, Kazan Muslims! It is difficult to find a rich man or a company leader among Muslims in Istanbul, but there are a few millionaires in Kazan!" [36].

The newspaper *Sabah,* issued in Istanbul, published an account of Mahmoud Esad Effendi's travels, using the information from Tatar newspapers. He acquainted the famous Tatar writer Fatikh Amirkhan with his interview and F.Amirkhan was dissatisfied with the way national issues were presented in the Ottoman Empire's publications. The *Sabah* disagreed with this opinion trying to prove that it was not based on real facts [37]. The *Sabah* quoted the Ottoman Empire publications that were reprinted in European newspapers. Besides, it was common practice to publish world news because

[5] Musa Zharullah Bigiev's works, prohibited by the theologian, are "Rehmet and ilyahiiya borhanlary", "Insannarnyn akyyde and ilyahiyalerene edges nazar", "Ozyn kunnerde uraza", "Kavaid-e fykhiya. For further information see [34: 13-16].

without such information any publication would be scant and eventless.

The Tatar press claimed that the Ottoman Empire's press was indifferent to 20 million kin living in Russia. In spite of the fact that there were many people in Kazan and its countryside who subscribed to the Ottoman Empire's newspapers, practically none of the Istanbul intelligentsia subscribed to Tatar newspapers and it was the sheer truth. Nowadays, there are very few copies of Tatar publications of that period in Turkish libraries. This testifies to the fact that the Ottoman Empire's intellectuals were indifferent to the publications about Tatars.

The editor-in-chief of the Istanbul newspaper *Sabah* Bedri Kemal Bey appreciated Mahmoud Esad Effendi's travel to Russia: "Mahmoud Esad Effendi's travel to the European part of Russia and the cities where Muslims reside is important both for friendship between the two countries where Muslims live and Ottoman-Russian political and social relations.

It is in the nature of people to forget the places that are nearest, the work that is easiest, and to connect their lives with the lands that are farthest, engage in business, which is out of their interest…. However, Turks are not concerned about Muslims of Russia, their ways of living, their needs, although Turks and Muslims of Russia have a lot in common: religion, language, relationships. Muslims of Russia are also Turkic people. Their progress means the progress of Turkic people. Their life is a part of Turkic people's life. Therefore, it is important to pay more attention to their social and literary life, as the cultural life of Muslims of Russia is connected with the future of the Turkic world. Recently the newspapers of the Ottoman Empire have published information about Muslims of Russia. It is also important to organize trips for Muslims of Russia to Turkey and from Turkey to Russia. Such trips are a good opportunity to establish cultural and social connections between the two Turkic worlds" [39].

Mahmoud Esad Effendi was impressed by the Russian hospitality and kindness shown towards him by the government. Everywhere he went, he was given a warm reception on the part of the government, military, police, and gendarmerie. He was also welcomed at the official offices and was at a loss for words when encountering the warmest reception and great respect shown by Muslims. In fact, the Muslims of Russia had never given such a big reception before. For this great respect he thanked them kindly [39].

He was delighted to see the progress in the commerce, culture and education of Russian Muslims. He noticed that the Muslims of Russia had no religious fanaticism but real religion and their nation [25].

These are some ideas of Russian Muslims concerning the Ottoman Empire and its relations with Russia: the desire of Russian Muslims was to establish relations of genuine friendship between Turkey and Russia as they loved and appreciated Turkey and the Turkic world. They wished to have a strong friendship with Turkey in science, culture and social life. It was reasonable because of a common religion, good relationships, and related languages. Due to the sincere and trusting relationships between Russia and the Ottoman Empire this friendship could be true and tension-free. Therefore, they longed for the friendship of two states and recollections of the past that should not have a negative impact on these positive developments.

When answering the questions of the editor-in-chief of the *Mir Islama* about Pan-Turkism and Pan-Islamism, and progress and conservatism among Muslims, Mahmoud Esad Effendi said: "Let's think about Pan-Turkism, Pan-Islamism as a political issue. If you ask me about forming one government for all Muslims and all Turkic people of the world I can say *no* and *it is impossible*. To live with such dreams is harmful both for Muslims and for Turkic people, particularly for Turkey. If you ask me: do Muslims and Turks wish to have a common scientific, cultural' and commercial relationship? – I answer *yes.* I consider it to be useful, not harmful. Muslims used to have such friendship and it keeps on" [25].

Mahmoud Esad Effendi also said that the idea of Pan-Turkism and Pan-Islamism was not approved by the government. He considered it to be a pipe-dream, and the idea was harmful as it worried Christian neighbours of Turkey. The editor-in-chief asked Mahmoud Esad Effendi's opinion of Shehbenderzade Hilmi Effendi's agitation in the government newspaper. Mahmoud Esad Effendi said that Shehbenderzade Hilmi Effendi was a writer who lived in his dreams. As there were many people dreaming everywhere, they were responsible for their publications.

Hilmi Pasha's journey to Russia contributed to good relationships between the Ottoman Empire and Russia. The 2$^{nd}$ Proclamation of the Constitution gained the approval and admiration of Russian democrats. Hundreds of people attended the celebration of the Istanbul Constitution in Moscow. The Chairman of the Duma A.Guchkov was

among those present at the celebration. Joseph Akchura published a number of articles on the popularity of the Ottoman Empire Constitution in Moscow.

Another important aspect of Hilmi Pasha and Mahmoud Esad Effendi's travels to the Volga-Ural was the fact that it was the first and the last journey to leave a lasting impression on the public. These travels were unique in their way. Zhelal Nuri İleri and Ahmed Zhevdet travelled in Russia (in 1910 and 1914 respectively) but these journeys did not draw any attention from the press. Hilmi Pasha and Mahmoud Esad Effendi's travels were covered both in the Muslim and Russian press as never before had there been any journeys of this kind to the Volga-Ural region.

The great respect showed to Mahmoud Esad Effendi was due to his authority and scientific recognition. Hilmi Pasha was less popular with Russian Muslims, therefore, the kudos offered to him was more due to his authority and the respect for the Ottoman Empire. Mahmoud Esad Effendi was known to many intellectuals of the Volga-Ural. His two volume work "Tagaddud-i zauzhat" had been translated into Tatar and some parts had been published in the journal *Shura* [42]. He also contributed articles to the Istanbul journal *Tagaruf-i muslimin*. When visiting Istanbul, Tatar intellectuals sought to meet him [43].

Hilmi Pasha and Mahmoud Esad Effendi's travels provided useful information about the relationships between Russia and Turkey and contributed to the development of spiritual, social, and religious connections between the related people – Volga-Ural Tatars and Turks. In addition, these travels, presented as news and covered in newspaper publications, provided an insight into the social and cultural life of that time and informed the readers about the lives of outstanding Tatar and Turkish people.

*Publications (news and articles) in the Tatar and Russian press of that time covering Hilmi Pasha and Mahmoud Esad Effendi's travels.*


1. Khilmi Pasha mädräsä-i Mökhämmädiyadä // Bäyanelkhak. 1910. № 602. 18 aprel'.
2. Khösäen Khilmi Pashanyö Kazanny ziyaräte // Bäyanelkhak. 1910. № 603. 20 aprel'.
3. Gabderräshit Ibrahim. Dävrä-i galäm Khösäen Khilmi Pasha // Bäyanelkhak. 1910. № 618. 25 aprel'.
4. Khilmi Pasha // Novoe vremya 1910. № 12226. 26 mart (8 aprel').
5. Khilmi Pasha v Peterburge // Novoe vremya. 1910. № 12227. 26 mart (9 aprel').
6. Peterburg 5 aprelya, Russko-turetskie otnosheniya // Novoe vremya. 1910. № 12237. 6 (19) aprelya.
7. Garif Kärimi. Khilmi Pasha Mäskäüdä // Vakyt. 1910. № 606. 17 aprel'.
8. Khilmi Pasha khakynda Kazan khalky // Vakyt. 1910. № 608. 24 aprel'.
9. Fatyykh Mortazin. Khilmi Pasha Samarada // Vakyt, 1910, № 609, 27 aprel'.
10. Abderrakhman Mostafin. Khilmi Pasha mäҗlesendä // Vakyt. 1910. № 610. 29 aprel'.
11. Khilmi Pasha vä Rusiya möselmannary // Vakyt. 1910. № 611. 1 may.
12. Khilmi Pashanyö mäktuby // Vakyt. 1910. № 624. 1 iyun'.
13. Peterburgta Khilmi Pasha khörmätenä ziyafät // Yoldyz. 1910. № 528. 15 aprel'.
14. Khilmi Pasha Kazanda // Yoldyz. 1910. № 529. 19 aprel'.
15. Khilmi Pasha Mädräsä-i Mökhämmädiyadä // Yoldyz. 1910. № 530. 21 aprel'.
16. Khilmi Pashanyö Kazanga kilesh khätiräläre // Yoldyz. 1910. №530. 21 aprel'.
17. Khilmi Pasha Samarada // Yoldyz. 1910. № 530. 21 aprel'.
18. Khilmi Pasha Varshavada // Yoldyz. 1910. № 532. 27 aprel'.
19. Khilmi Pasha shäräfenä «Novoe vremya» gazetasynyö ziyafäte// Nur. 1910. № 190. 8 aprel'.
20. Khilmi Pashanyö «Novoe vremya»ny ziyaräte khakynda // Yoldyz. 1910. №539. 13 may.
21. Җ.A. Khösäen Khilmi Pasha Rusiyadä // Täržeman. 1910. № 18. 30 aprel'.
22. Khilmi Pasha // Novoe vremya. 1910. № 12226. 26 mart (8 aprel').
23. Khilmi Pasha v Peterburge // Novoe vremya. 1910. № 12227. 26 mart (9 aprel').
24. Peterburg 5 aprelya, Russko-turetskie otnosheniya // Novoe vremya. 1910. № 12237. 6 (19) aprel'.
25. «Mir islama» zhurnaly vä Mäkhmüd Äsad // Vakyt. 1913. № 1312. 4 oktyabr'.
26. Fatyykh Ämirkhan. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän «Koyash» dachasynda äögämä // Koyash. 1913. № 188. 5 avgust.
27. Zäkäriya Sadretdinov. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän yuldashlygym istälekläre // Koyash, 1913, № 189, 6 avgust, b.2.
28. Zäkäriya Sadreddinov. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän yuldashlygym istälekläre // Koyash, 1913, № 190, 7 avgust, b.2.
29. Zäkäriya Sadreddinov. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän yuldashlygym istälekläre // Koyash. 1913. № 195. 15 avgust.
30. Zäkäriya Sadreddinov. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän yuldashlygym istälekläre // Koyash. 1913. № 196. 16 avgust.
31. Kärim Säed. Mäkhmüd Äsad Äfände // Koyash. 1913. № 199. 25 avgust.
32. Mäkhmüd Äsad äfände vä Rusiya möselmannary // Koyash. 1913. № 217. 15 sentyabr'.

33. Mäkhmüd Äsad äfände vä Rusiya möselmannary // Koyash. 1913. № 218. 16 sentyabr'.
34. Dakhili (echke) khäbärlär// Tärжeman. 1910. № 15. 9 aprel'.
35. Mäkhmüd Äsad äfände // Tärжeman. 1913. № 193. 3 sentyabr'.
36. Bezneö khakta ni dilär // Tärжeman. 1913. № 202. 13 sentyabr'.
37. Islamchylyk törkchelek // Tärжeman. 1913. № 213. 28 sentyabr'.
38. Mäkhmüd Äsad äfände Finlyandiyadä // Täržeman. 1913. № 277. 17 dekabr'.
39. Mäkhmüd Äsad äfändeneö kileshe // Yoldyz. 1913. № 1017. 4 avgust.
40. Mäkhmüd Äsad äfändeneö kileshe // Yoldyz. 1913. № 1018. 6 avgust.
41. Mäkhmүd Äsad äfändeneö kileshe // Yoldyz. 1913. № 1021. 13 avgust.
42. Mäkhmüd Äsad äfändeneö fikere //Yoldyz. 1913. № 1038. 24 sentyabr'.
43. Mäkhmüd Äsad äfändeneö fikere // Yoldyz. 1913. № 1040. 29 sentyabr'.
44. Fatyykh Kärimi. Mäkhmüd Äsad äfände Orenburgta // Vakyt. 1913. № 1263. 31 iyul'.
45. Fatyykh Kärimi. Mäkhmüd Äsad äfände Orenburgta // Vakyt. 1913. № 1264. 1 avgust.
46. Fatyykh Kärimi. Mäkhmüd Äsad äfände Orenburgta // Vakyt. 1913. № 1265. 2 avgust.
47. Fatyykh Kärimi. Mäkhmüd Äsad äfände Orenburgta // Vakyt. 1913. № 1266. 3 avgust.
48. Mäkhmüd Äsad äfände Ufada // Vakyt. 1913. № 1267. 4 avgust.
49. Mäkhmüd Äsad äfände Mäskäüdä// Vakyt. 1913. № 1273. 13 avgust.
50. Abdullah äl-Mazi. Mäkhmüd Äsad äfände bin Ämin äl-Säydishähri // Din vä mägyyshät. 1913. № 31. avgust. 491-492 b.
51. Din үzgärtү // Din vä mägyyshät. 1913. № 32. avgust. 517-521 b.
52. Mäkhmüd Äsad äfände yahut islakhat-y diniya // Din vä mägyyshät. 1913. № 40. noyabr'. 633-634 b.
53. Mäkhmüd Äsad äfände yahut islakhat-y diniya // Din vä mägyyshät. 1913. № 42. noyabr'. 664-665 b.

**References**

1. *Celal Nuri.* Şimal Hatıraları. İstanbul, 1330. 128 s. (in Turkish)
2. *Kharis Fäyzi.* Sadretdin bäygä khitab (möräžägat'). Ölfät. 1906. №27. 26 iyun'. (in Tatar)
3. *Akchura Y.* Siriyadän II. Vakyt. 1913. № 1183. 24 aprel'. (in Tatar)
4. *Devlet N.* Türkiye'ye Katkıda Bulunan Tatar-Başkurtlar // Türkiye Cumhuriyeti Devleti'nin Kuruluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri. Kayseri: Erciyes Üniversitesi, Türk Dünyası Araştırmaları Merkezi, 1996. 468 s. (in Turkish)
5. Mäkhmüd Äsad äfändeneŋ kileshe // Yoldyz. 1913. № 1017. 4 avgust. (in Tatar)
6. *Kärim Säid*. Mäkhmüd Äsad äfände // Koyash. 1913. № 199. 25 avgust. (in Tatar)
7. *Aydyn M*. Khösäen Khilmi Pasha // Türkiye Diyanet Vakfı İslam Ansiklopedisi, 18. İstanbul, 1998. 550 b. (in Tatar)
8. *Erdogdu A*. Makhmud Esad Säydishähri // Türkiye Diyanet Vakfı İslam Ansiklopedisi, 37. İstanbul, 2009. 585 b. (in Tatar)
9. Khilmi Pasha // Nur. 1910. № 189. 31 mart. (in Tatar)
10. *Mortazin F*. Khilmi Pasha Samarada // Vakyt. 1910. № 609. 27 aprel'.
11. *Ibrahim G*. Dävrä-i galäm Khösäen Khilmi Pasha // Bäyanelkhak.1910. № 618. 25 may. (in Tatar)
12. Peterburgta Khilmi Pasha khörmätenä mäžles. // Yoldyz. 1910. № 528. 15 aprel'.
13. Khilmi Pashanyŋ "Novoe vremya"ny ziyaräte khakynda // Yoldyz. 1910. № 539. 13 may. (in Tatar)
14. *Akchura Y.* Yaktashlaryma khatlar // Äkhbar. 1908. № 13. 11 yanvar'. (in Tatar)
15. *Kärimi G*. Khilmi Pasha Mäskäüdä // Vakyt. 1910. № 606. 17 aprel'. (in Tatar)
16. Khilmi Pasha Varshavada // Yoldyz. 1910. № 532. 27 aprel'. (in Tatar)
17. Khilmi Pasha Kazanda // Yoldyz. 1910. № 529. 19 aprel'. (in Tatar)
18. Tatarstan milli arkhivy. Fond 1, delo 4, saklanu berämlege 4240. (in Tatar)
19. Khilmi Pasha Mädräsä-i Mökhämmädiyadä // Yoldyz. 1910. № 530. 21 aprel'. (in Tatar)
20. Khilmi Pasha Kazanda // Vakyt. 1910. № 607. 22 aprel'. (in Tatar)
21. Khösäen Khilmi Pasha Rusiyadä // Täržeman. 1910. № 18. 30 aprel'. (in Tatar)
22. Tatarstan Milli Arkhivy. Fond 1, delo 4, saklau berämlege 5468. (in Tatar)
23. Hakkımızda ne diyorlar // Tercüman. 1913. sayı 202. 13 Eylül. (in Turkish)
24. *Ämirkhan F*. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän "Koyash" dachasynda äŋgämä // Koyash. 1913. № 188. 5 avgust. (in Tatar)
25. *Mäkh*müd Äsad äfände Finlyandiyadä // Täržeman. 1913. № 277. 17 dekabr'. (in Tatar)
26. *Kärimi F*. Mäkhmüd Äsad äfände Orenburgta // Vakyt. 1913. № 1266. 3 avgust. (in Tatar)
27. *Abdullah äl-Mazi*. Mäkhmüd Äsad Äfände bin Ämin äl-Säydishähri // Din vä mägyyshät. 1913. № 31. avgust. (in Tatar)
28. Din üzgärtü // Din vä mägyyshät. 1913. № 32. avgust. (in Tatar)
29. "Mir islama" zhurnaly vä Mäkhmüd Äsad // Vakyt. 1913. № 1312. 4 oktyabr'. (in Tatar)
30. Makhmud Esad efendi v Rossii // Mir Islama. 1913. № 7. S. 462-483. (in Russian)
31. Mäkhmüd Äsad äfände Ufada // Vakyt. 1913. № 1267. 4 avgust. (in Tatar)
32. *Sadretdinov Z*. Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän yuldashlygym istälekläre // Koyash. 1913. № 189. 6 avgust. (in Tatar)

33. *Aliev Ä.* Mäkhmüd Äsad äfände Mäskäüdä // Vakyt. 1913. № 1273. 13 avgust. (in Tatar)
34. *Türkoğlu İ.* Musa Carullah Bigi'nin dört kitabının hikayesi // Türk Dünyası Tarih Dergisi. 1997. sayı 131. Kasım. S. 13-16. (in Turkish)
35. *Sadreddinov Z.* Mäkhmüd Äsad äfände khäzrätläre belän yuldashlygym istälekläre // Koyash. 1913. № 190. 7 avgust. (in Tatar)
36. Mäkhmüd Äsad äfände vä Rusiya möselmannary // Koyash. 1913. № 217. 15 sentyabr'. (in Tatar)
37. Matbuat-ı Osmaniye ve Mahmud Esad Efendi // Sabah. 1913. sayı 8611. Eylül. (in Tatar)
38. Koyash, 1913, № 218, 16 sentyabr'. (in Tatar)
39. Bezneŋ khakta ni dilär // Täržeman. 1913. № 201. 12 sentyabr'. (in Tatar)
40. *Akchura Y.* Yuk-bar // Vakyt. 1909. № 524. 26 sentyabr'. (in Tatar)
41. *Äsad M.* Tarikh-i islam, I. Tom. Kazan: Milliyat matbagasy 1908. 190 b.; Tarikh-i islam, II. tom, Kazan: Milliyat matbagasy 1908. 80 b. (in Tatar)
42. Izdivaž (öyläneshü) mäs'äläseneŋ fälsäfäse // Shura. 1911. № 1. (in Tatar)
43. *Kärimi F.* Mäkhmüd Äsad äfände Orenburgta // Vakyt. 1913. № 1263. 31 iyul'. (in Tatar)

---

# ХӨСӘЕН ХИЛМИ ПАША ҺӘМ МӘХМҮД ӘСАД ӘФӘНДЕНЕҢ ИДЕЛ-УРАЛ СӘЯХӘТЛӘРЕ

**Исмаил Түркоглу,**
Мимар Синан сәнгать университеты,
Төркия, 34427, Истанбул ш., Фындыклы,
turkogluismail@yahoo.de.

Мәкаләдә Төркиянең элеккеге бөек вәзире (премьер-министры) Хөсәен Хилми Паша һәм финанслар министры Мәхмүд Әсад әфәнденең XX гасыр башында Россиягә, аерым алганда, Идел-Урал төбәгенә сәяхәте тасвирлана. Хилми Паша 1910 елда сигез ай дәвамында Европага сәяхәте вакытында Россиянең Петербург, Мәскәү, Түбән Новгород, Самара кебек шәһәрләр белән беррәттән, Казанда була. Сәяхәте вакытында Россия мөселманнарының рухи һәм мәдәни тормышы белән таныша. Бу үз чоры өчен зур вакыйга була: Казан тарихында беренче тапкыр Госманлы пашасы рәсми рәвештә кабул ителә һәм аңа югары дәрәҗәдә ихтирам күрсәтелә.

Мәкаләнең икенче өлешендә Мәхмүд Әсад әфәнденең Идел-Урал төбәгенә ясалган сәяхәте бәян ителә. Автор бу сәяхәтнең шул чор вакытлы матбугатында чагылышына анализ ясый. Хилми Паша һәм Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәтләре, бер яктан, Русия һәм Төркия дәүләтләре арасындагы мөнәсәбәтләр хакында мәгълүмат бирсә, икенче яктан тугандаш халыклар – Идел-Урал буе татарлары һәм төрекләр арасындагы рухи, иҗтимагый, дини бәйләнешләрне тирәнәйтүгә, кан-кардәшлек һәм туганлык җепләрен ныгытуга хезмәт итә. Аннан тыш шушы сәяхәтләр уңаеннан матбугатта басылган хәбәрләр һәм мәкаләләр укучыга шушы чорның мәдәни, рухи тормышы, татар һәм төрек халыкларының мәшһүр затлары хакында бай мәгълүмат бирә.

**Төп төшенчәләр**: Россия мөселманнары, Идел-Урал төбәге, милли мәгариф, мәктәп-мәдрәсәләр, татар зыялылары, Россия – Госманлы дәүләте мөнәсәбәтләре.

XIX гасыр ахыры һәм бигрәк тә XX гасыр башларында Казан, Уфа, Самара, Оренбург кебек, татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрдән Госманлы дәүләтенең Истанбул, Бәйрут, Бәгъдад, Селяник (Солоники), Мәккә, Мәдинә кебек шәһәрләренә белем алу өчен, йөзләрчә укучы килә торган булган. Шул чорның татар матбугатында басылган язмалардан аларның саны шактый күп булганлыгы аңлашыла. 1910 елдагы сәяхәте вакытында Казанда булган Җәлал Нури Иләри, госманлы мәктәп мәдрәсәләре реформалар юлы белән бераз яңартылса, Русиядән ел саен ике мең укучы килергә мөмкин булуын [1: 118], Габдеррәшит Ибраһимов исә, 1906 елда Истанбулдагы һәр мәктәптә 5-10 татар укыганлыгын, хәтта Мәрҗан урта мәктәбендә татар укучылар өчен аерым бер сыйныф ачылганлыгын белдерә [2]. Бәйруттагы Американ колледжында 1913 елда 12 татар укучысы була [3: 2-3]. Татар укучылары Истанбулдагы Мәрҗан, Вәфа урта мәктәпләренә, Мәктәб-и Султани (Солтан мәктәбе) һәм Солоники урта мәктәбенә өстенлек биргәннәр. Бу укучылар арасында иң танылганнары – Гобәйдулла Бубый, Фатих Кәрими, Харис Фәйзи, Шәриф Камал, Мәхмүт Алмаев, Габдрахман Кәрим, Габдрахман Садый һәм Габдеррәшит Ибраһимов кебек татар

зыялылары була. Болардан тыш, Истанбулның башка мәктәпләрендә, Бәгъдад, Мәккә һәм Мәдинә кебек шәһәрләрдәге мәдрәсәләрдә белем алучы күпсанлы татар укучылары да булган. Ләкин боларның санын якынча гына атау да кыен. Идел-Урал төбәгендәге җәдитчелек хәрәкәте Госманлы дәүләтендә белем алып кайткан яшьләрнең фикерләреннән көч алып торган. Госманлыга укырга килгән Муса Акъегетзадә, Хәлим Сабит Сибай, Хәмит Зөбәер Кошай һәм Әхмәт Таҗетдин кебек яшьләр исә, ватаннарына кире кайтмыйча, бәлки дә кайта алмаганга, Төркиядә калганнар, төрекләрнең мәгарифе һәм мәдәнияте үсешенә әһәмиятле өлеш кертkәннәр [3: 2-3][1].

Укучы яшьләрдән башка тагын, төрле сәбәпләр белән, аеруча Хаҗга бару юлында, Истанбулда туктап госманлы зыялылары белән күрешеп, фикер алышып торган зыялыларның саны да аз түгел. Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Галиәсгар Камал, Дәрдемәнд, Муса Бигиев, Зыя Камали, Абдулла Баттал Таймас, Гаяз Исхакый һәм Габдулла Бубый кебек зыялылар төрле чорларда Истанбулда яшәгәннәр.

Татар зыялыларының юлы һәрвакыт Истанбул аша үтсә дә, Госманлы зыялылары Идел-Урал төбәге белән бик артык кызыксынмаганнар. 1905 елдан оеша башлаган татар матбугатында да, Төркия әдип һәм галимнәренең Русиягә килмәүләре, татарларның әдәби, икътисади, гыйльми һәм иҗтимагый хәлен аңларга теләмәүләре тәнкыйть ителгән [5]. Госманлы матбугатының төньяк төркиләренә бер тиенлек тә илтифат күрсәтмәвеннән, Истанбулга килгән татар галимнәренә Бохараның борынгы муллаларына күрсәтелгән кадәр дә игътибар ителмәвеннән зарланганнар [6].

Бу төбәкне госманлы зыялыларыннан бары тик дүрт кеше килеп күргән: Җәлал Нури Иләри, Садры-сабык һәм Айан мәҗлесе әгъзасы Хөсәен Хилми Паша [7: 550-551][2], Дәфтәр-и хакани министры Мәхмүд Әсад әфәнде [8: 25-27][3] һәм «Икъдам» газетасының хуҗасы Әхмәд Җәүдәт.

Хилми Паша 1910 елның 12 гыйнварында тәмамланган баш вәзирлегенең икенче чорыннан соң, якынча сигез ай буе дәвам иткән Европа сәяхәтенә чыга. Бу сәяхәте вакытында Франция, Англия, Германия, Русия, Австрия һәм Италия кебек төрле илләрне гизә. Паша үз шәхси кызыксынуы белән, гайре рәсми сурәттә Европа һәм Русияне беренче тапкыр килеп күргән беренче Госманлы дәүләт кешесе була. Пашаның 1910 елның 25 мартында Петербургтан башланган Русия сәяхәтенең бернинди дә рәсми үзенчәлеге булмаса да, аңа биредә дәүләт эшлеклеләренә лаек мөгамәлә күрсәтелә. Хилми Паша сәяхәте көннәрендә Петербург, Мәскәү, Казан, Самара, Харьков, Варшава кебек шәһәрләрдә була.

Паша, шул чор Русиясенең премьер-министры Столыпин ярдәме белән, 1910 елның 29 мартында Царское селода патша Николай II белән күрешә [9]. Хилми Пашаның патша белән

---

[1] Бу турыда өстәмә мәгълүмат алу өчен карагыз: [4: 161-173]

[2] Хөсәен Хилми Паша (1855-1923) озак еллар төрле вилаятьләрдә санҗак башлыгы булып тора, Абделхамид II Ямәндә чыккан башкүтәрүне бастырыр өчен, Хилми Пашаны 1898 елда Ямән вәлисе (губернаторы) итеп куя һәм 1899 елда исә вәзирлек дәрәҗәсе бирә. Биш ел Ямәндә вәли булган Хилми Паша бер һөҗүм вакытында авыр яралана һәм эш урынын калдырып китәргә мәҗбүр була. Аннан соң 6 ел Румели өлкәсендә инспектор була, II Мәшрутият игълан ителгәннән соң, Эчке эшләр министрлыгы вазифасына билгеләнә. 1909 елның февралендә Камил Паша җитәкчелегендәге совет властьтан куылганнан соң, 2 ай дәвам иткән баш вәзирлегенең беренче чоры башлана. 31 март вакыйгасы сәбәпле эшеннән китә. 1909 елның маенда тугыз ай дәвам иткән баш вәзирлегенең икенче чоры башлана. 1910 елның 12 гыйнварында баш вәзирлеге тәмамлана. Шуннан соңгы елларда сенат әгъзасы, хокук министры һәм Венада илче вазифаларын башкара. Венада яшәп кала һәм 1923 елда биредә вафат була. Җәсәде Истанбулга китерелеп, Бишекташтагы Яхъя Әфәнде Дәргаһы зиратында күмелә. Бу турыда тулырак мәгълүмат: [7: 550-551].

[3] Мәхмүд Әсад Әфәнде (1856-1918), ислам дин галиме гаиләсендә туып үсә. Истанбулда урта мәктәпне бетереп, Фатих мәдрәсәсендә дин, хәрби урта мәктәптә дөньяви фәннәр буенча белем ала. Хәрби мәктәпнең штаб хәзерлеге сыйныфларына да йөреп, математика укытучысы дипломына ия була. Бу урта мәктәптә укыган вакытта яңа ачылган хокук мәктәбенә дә дәресләргә йөри һәм аны да беренчеләр рәтендә тәмамлый. Берара Анадолуның (эчке Төркия, Анатолия) төрле төбәкләрендә мәктәпләрдә укытучы, махкәмәләрдә судья булып эшли. 1896 елда Истанбулга килеп Хокук мәктәбенә укытучы булып урнаша. II Мәшрутияттән соң, Дәфтәр-и Хакани (финанслар) министры итеп билгеләнә. Берничә ел Хокук министрлыгында вәкил булып тора, 1914 елда Спарта төбәгеннән милләт вәкиле (депутат) итеп сайлана. 1918 елда Истанбулда вафат була. Хокук һәм ислам тарихы турында язылган бик күп хезмәтләре бар. Бу турыда тулырак мәгълүмат: [8: 25-27].

күрешүенә бәйле мәгълүматлар сакланмаган. Бары тик Самарада «Вакыт» газетасы хәбәрчесе Фатих Мортазин белән булган әңгәмәсендә, патша белән күрешеп сөйләшкәндә, Русия мөселманнарының Русия дәүләтенә булган тугрылыкларыннан гаять канәгать калганлыгын патшага белдерүе турында әйтә [10: 3].

Берничә көн соңрак, Столыпин, үз өенә аш мәҗлесенә чакырып, Пашаны Русиянең алдынгы сәясәтчеләре һәм танылган язучылары белән таныштыра [11: 3]. Петербургта Хилми Пашаны мәҗлесләренә чакырып кунак иткән кешеләр арасында генерал Шәйхгали Хатани һәм Гөлсем Бикә кебек мөселман җәмәгатенең алдынгы шәхесләре дә була. Бу мәҗлесләргә Дума әгъзасы булган мөселман вәкилләрнең һәммәсе дә катнаша. Паша белән күрешергә килүчеләр арасында Петербургта белем алучы мөселман кызлар да бар. Паша, мөселман кызларның югары белем алуларын күреп, бик канәгать булуын белдерә.

Пашаның Петербургтагы иң әһәмиятле эшләреннән берсе – «Новое время» газетасы редакциясенә баруы була. Редакция идарәсе аның хөрмәтенә 1910 елның 4 апрелендә шәһәрнең иң мәшһүр кунакханәләренең берсендә мәҗлес оештыра. Хилми Паша мәҗлескә илче Тархан Паша, илчелек киңәшчесе Рагыйб Рәүф бәй, икенче сәркатип Әсад бәй, хәрби атташе Рәмзи бәй, тәрҗемәче Линевич һәм Төркия консулы Генри Балбин белән бергә килә. Мәҗлескә чакырылган кешеләр арасында Дума рәисе Александр Гучков, Дума әгъзалары А.Стахович, Н.Шубинский, Н.Сазанов, И.Потоцкий һәм Садри Максуди, чит ил газеталары журналистларыннан *Le Figaro* газетасы хәбәрчесе Маршан, *Time* газетасы хәбәрчесе Вильтон һәм башка тагын берничә дәрәҗәле чит ил газета һәм агентлык хәбәрчеләре дә була [12].

Хилми Пашаның Петербургта «Новое время» газетасы редакциясенә очрашуга баруы һәм идарә оештырган мәҗлестә катнашуы Истанбулда сүз һәм гайбәт таралуга сәбәп була. Шул чор матбугатында бу вакыйгага нисбәтле бәхәсләргә шактый урын бирелә. Кайбер газеталар Паша хөрмәтенә мәҗлес оештырылуны һәм Пашаның анда катнашуын мәгънәсез эш дип бәялиләр, чөнки «Новое время» – рус милләтчеләренең матбугат органы – Думага каршы һәм Русиядә яшәүче рус булмаган милләтләргә дустанә мөнәсәбәттә булмаган газета була. Бигрәк тә Меньшиков дигән хәбәрченең Төркиядәге реформалар турында тискәре фикерләр язуы һәм, гомумән, Госманлы дәүләтенә каршы булуы сәбәпле, бу күрешүне зарарлы дип саныйлар [13: 2]. Русия мөселманнары да «Новое время»ны укуны бик зур гөнаһ дип беләләр[4]. Тик озак еллар Петербургта яшәгән һәм Русия сәясәтен якыннан таныган Габдеррәшит Ибраһим: «Паша «Новое время» газетасының хуҗасы А.Суворин оештырган мәҗлескә килмәгән булса, ихтимал, Идел буе сәяхәтен дәвам итә алмаган булыр иде» [11: 3]. – дип яза. Г.Ибраһимның бу фикерен раслый торган кайбер дәлилләр дә бар. Мәсәлән, Пашага Түбән Новгород шәһәрендә яшәүче мөселманнар белән күрешү мөмкинлеге бирелми, бары тик шәһәрнең кайбер истәлекле урыннарын губернатор белән бергә караганнан соң, ул Казанга озатыла [15: 3]. Югыйсә, Түбән Новгород мөселманнары Пашаның үз шәһәрләренә киләчәген Мәскәүдә ишетеп кайтып, тарихта беренче тапкыр Госманлы пашасын кунак итәчәкләрен аңлаганга, бик зурлап әзерләнгән булалар. Хилми Пашаның Самарадан Оренбург яки Әстерхан шәһәрләренә, аннан соң Урта Азиягә китү теләге була [16: 2]. Ләкин, ихтимал, рөхсәт бирелмәү сәбәпле, сәяхәт планын үзгәртеп, яңадан Европага китә һәм аннан Истанбулга кайта.

1910 елның 8 апрелендә Хилми Паша Петербургтан Мәскәүгә китә. Пашаны Мәскәү

[4] Йосыф Акчура Русиядә яшәгән елларында «Новое время»ны укыганы өчен, башына килгән бәлаләр турында шул рәвешле сөйли: ««Новое время»ны, бигрәк тә аның флюгеры Меньшиковны уку, бүгенге көндә гөнаһы кәбаир булып саналганын бик яхшы беләм. «Новое время»ны сатып алганда, сатучылар да бик начар күз белән карыйлар. Әгәр башың авырып өйдән чыга алмасаң, базарга барып «Новое время» алып кайтырга дип күрше малаеннан сорасаң алмый, ул да ояла. Хәтта фәкыйрь булса да, «Товарищ» яки «Рус» газеталарын аяк ялсыз да алып китерәчәк, «Новое время»ны исә акча бирсәң дә, кулына да алырга риза түгел! (Моны бары тик күзаллау дип кенә уйламагыз, берничә мәртәбә башымнан үтте). Шулай булса да, мин рус газеталарын, ярым-ярты аңлый башлаганнан бирле, акчам булган саен, кайда булсам да, Казанда, Мәскәүдә, Петербургта, Кырымда, хәтта чит илләрдә дә, бер көн калдырмыйча, «Новое время»ны алып укырга тырышам. Үзем генә укып та калмыйм, дусларыма да «Новое время»ны, «Вакыт»ның гыйбарәсе белән «хөкүмәт ашчысын» укырга киңәш итәм! Башта миңа ачуланалар, карагруһ нәшрият фикерен җәясең диләр, шулай да мин фикеремнән кире кайтмыйм, үз сүземдә торам [14: 2].

вокзалында каршыларга Төркиянең Мәскәүдәге баш консулы Палаков, Мәскәү мөселманы – чыгышы белән Томск шәһәреннән булган Исхак Мохтаровтан башка кеше килми, чөнки Хилми Пашаның Мәскәүгә киләсе вакыты алдан ачык билгеле булмый.

Хилми Паша Мәскәүдәге беренче көнендә шәһәрнең истәлекле урыннарын карап йөри, кичен Зур театрга бара. Анда русларның «Жизнь за царя» милли операсын карый. Иртәгесе көнне Мәскәүнең беренче мәхәлләсендәге мәчеттә җомга намазын кыла. Җомга намазына килгән мөселманнар Хилми Пашага хөрмәтләрен белдерәләр. Мәскәүгә килүенең икенче көнендә шәһәрнең дәрәҗәле мөселманнарының берсе Хаҗи Хөсәен Байбиков үз өендә Паша хөрмәтенә мәҗлес оештыра. Мәҗлескә Мәскәү мөселманнарының алдынгылары, университет укучылары, Баку миллионеры Әсадуллаев, Томск сәүдәгәре Исхак Мохтаров, Екатеринбургтан Садретдин Агафуров, Казаннан Мөхәммәтҗан Кәримов һәм башка тагын берничә дәрәҗәле сәүдәгәр катнаша. Аш вакытында, сәясәткә кермичә генә, ысулы җәдид һәм ысулы кадим, өс киеме, мәктәпләрдә укытылырга тиешле дәресләр, тел мәсьәләсе кебек төрле темаларга сөйләшү була. Тел мәсьәләсендә Хилми Паша төрек һәм татар телләрен берләштерү яклы икәнен белдерә. Моның юлын ул төрекләрнең татар теленнән, татарларның исә, туган телләренә караганда күпкә баерак булган төрек теленнән күпләп сүз алуда күрә. Уртак төрек-татар телен барлыкка китерүне яклый. Мондый уртак телнең ни өчен кирәклеген шул рәвешле аңлата: «Беренчедән, без барыбыз да мөселманнар, бер-беребез белән күрешеп сөйләшүебез, танышуыбыз кирәк. Икенчедән, мин өмет итәм ки, Русия мөселманнары Төркия белән сәүдә итә башларлар. Төркия белән сәүдә итү татарлар өчен файдалы булачак. Сәүдә арту белән, ике телнең бер-берсенә якынаюы да артачак» [15: 3].

Хилми Паша 1910 елның 15 апрелендә Түбән Новгородтан Казанга китә. Пашаны губернатор ярдәмчесе Георгий Болеславович Петкевич, жандарм идарәсе башлыгы Константин Иванович Калинин, шәһәр башлыгы Сергей Андреевич Бекетов, куркынычсызлык саклау идарәсе башлыгы Алексей Иванович Васильев, Казан матбугат бүлегеннән Николай Иванович Ашмарин, Казан университеты профессоры Николай Федорович Катанов каршылый. Пашаның Казанга киләсе көне турында хәбәрдар булмаганлыктан, аны каршыларга килүчеләр арасында Казан мөселманнары күренми. А.Васильев, Н.Ашмарин һәм Н.Катанов Казанда үткәргән өч көн буе Пашаны беразга да ялгыз калдырмыйлар, Казан губернаторы Михаил Васильевич Стрижевский да 16-17 апрель көннәрендә Хилми Пашаның Казандагы барлык күрешүләре вакытында аның янында китми [17].

Хилми Паша кунакханәдәге бүлмәсенә урнашканнан соң, Н.Катанов белән Н.Ашмарин Пашадан шәһәрнең кайсы урыннарын, нинди җирләрен күрергә теләгәнлеге турында сорашалар. Паша Көнчыгыш телләре академиясе, завод-фабрикалар, Благовещенский чиркәве, Сөембикә манарасы, шәһәр музее, татар мәхәлләсе һәм мәчетләрне күрергә теләге булуын белдерә. Бергә фикерләшкәннән соң, 15 апрель көнне шәһәр үзәгендәге истәлекле урыннарны, 16-17 апрельләрдә фабрикаларны, шәһәрнең татар мәхәлләләрен, мәдрәсә һәм мәчетләрне барып күрү турында хәл ителә. Полиция идарә башлыгына план белдерелә һәм кирәкле чаралар күрергә кушыла. Н.Катанов Хилми Пашага шәһәрнең истәлекле җирләре һәм тарихи кыйммәте булган урыннары турында язылган дүрт китап бүләк итә [18].

Паша Казан сәяхәтен Казан университеты китапханәсеннән башлый. Бу бик бай китапханә Пашаның игътибарын җәлеп итә. Ул мондагы бер мөселман кабер ташы язуын, цилиндр рәвешендәге һәм 50 кисәк тирегә язылган иврит телендәге «Тәүрат»ны якыннан тикшереп карый. Китапханәдән университетның музеена керәләр. Биредә Пашаны университет ректоры һәм ректор ярдәмчесе каршылый. Музейда Паша борынгы рус һәм сасани акчалары белән якыннан кызыксына. Музей карарга килүчеләр дәфтәренә университетны күрүдән канәгатьлек тоюын белдереп, берничә юл язу язып калдыра. Тик Казан университетында белем алучы мөселман укучыларның саны аз булу Пашаны гаҗәпләндерә, рус мәктәп һәм университетларының мөселманнар өчен дә ачык булуына карамастан, аларның моннан файдаланмауларына борчылуын белдерә.

Шәһәр музее, Благовещенский чиркәве һәм Сөембикә манарасын барып күргәннән соң, губернаторның өенә барып кофе эчәләр һәм кунакханәгә кайталар. Анда Пашаны Юнысовлар гаиләсе төзеткән мөселман ятимнәр йорты мөдире Мөхәммәтрәхим Юнысов, сәүдәгәрләр Бәдретдин Апанай, Исмәгыйль Үтәмеш, «Йолдыз» газетасы

редакторы Һади Максуди һәм күпсанлы мөселман, рус кешеләре көтеп тора. Сәүдәгәрләр Пашага 16 апрель көнне кичен Сәүдәгәрләр клубында аның хөрмәтенә аш мәҗлесе үткәргергә теләүләрен белдерәләр. Паша бу тәкъдимне рәхмәт әйтеп кабул итә. Бәдретдин Апанай Паша хөрмәтенә 15 апрель көнне бик зурлап мәҗлес корырга теләвен белдерә, ләкин Паша бу килүенең рәсми булмавын сәбәп итеп баш тарта. Шуннан соң, Бәдретдин Апанай Пашаны 16 апрель көнне өенә өйлә ашына чакыра. Һади Максуди үз нәшриятында басылган егермеләп әсәрен бүләк итә. Паша әсәрләрне зур кызыксыну белән шунда ук карап чыга, кайбер имля хаталары буенча фикерләрен белдерә, Максудины бу әсәрләре белән тәбрик итә. Төрек һәм татар телләре арасындагы якынлык турында башланып киткән сөйләшү бераздан җәдит-кадим көрәше мәсьәләсенә күчә. Паша бу вакыйгаларның Төркиядә дә булуын әйтә, вакыт үтү белән, кадимчеләрнең бу гауганы туктатачакларына ышаныч белдерә.

16 апрельдә Хилми Паша губернатор, полиция идарә башлыгы, Н.Ашмарин, Н.Катанов, Ахунд Абызов, Һади Максуди, Исмәгыйль Кәримов белән бергә мөселман мәхәлләләрен карап йөриләр. Башта Мөхәммәдия мәдрәсәсенә баралар. Хилми Паша бу мәдрәсәдә башлангыч беренче сыйныфтан башлап дүрт сыйныфка, урта бүлемдәге дүрт сыйныфка һәм урта югары ике сыйныфка, ягъни барысы ун сыйныфка кереп карап чыга. Һәр сыйныфта укучыларга сораулар бирә, җавапларыннан канәгать калып, Паша укучылар алдында белем алу һәм фәннәр турында чыгыш та ясый. Озатып йөрүчеләр дә Паша белән бергә бөтен сыйныфларга кереп чыгалар. Мәдрәсәдә күрешүләр вакытында кадим-җәдит мәсьәләсе дә көн тәртибенә чыга. Һади Максуди бу форсат белән, кадимчеләрнең җәдитчеләрне хөкүмәткә шикаять итүләре турында да әйтә. Мөхәммәдия мәдрәсәсенең оештыручысы һәм эшләтүчесе Галимҗан Баруди бу вакытта мәдрәсәдә булмый. Полиция башлыгы аны чакыртып китертә һәм Паша белән таныштыра [19]. Паша Мөхәммәдия мәдрәсәсеннән канәгать кала. Аннан бертуган Кәримовлар матбагасына баралар. Анда хәрефләр кассасын һәм басылып чыккан кайбер әсәрләрне карыйлар.

Паша һәм юлдашлары бераздан Әҗем мәчетенә юнәләләр. Мәчет Пашаны күрергә теләгән халык белән тулы була. Мәчеттән чыгып, Арслановларның сабын заводына юл алалар. Паша Казан мөселманнарының борынгы заводларыннан берсе булган бу сабын заводын бик игътибар белән карап йөри. Җомга намазы якынлашканга, Паша намаз кылу өчен, Печән базары мәчетенә керә. Намаздан соң, Бәдретдин Апанай өенә көндезге ашка китәләр. Аш мәҗлесендә Паша моннан соң, Русия-Госманлы дуслыгының артуы, көчәюе өчен хезмәт итәчәген белдерә. Берничә завод-фабриканы караганнан соң, Юнысовлар гаиләсенең ятимнәр йортын барып күрәләр һәм Мөхәммәтрәхим Юнысов өендә чәй эчәләр. Бирeдән губернатор сараена китәләр, ә кич сәгать сигездә Казан мөселманнары тарафыннан Паша хөрмәтенә оештырылган аш мәҗлесенә клубка баралар. Мәҗлес төнге 11гә кадәр дәвам итә. Кичке аш вакытында күтәрелгән иң әһәмиятле тема – Казан шәһәр идарәчеләре белән татарлар арасында якын мөнәсәбәтләр моннан соң да өзелмәсен иде дигән теләк була. Икенче көнне Паша һәм губернатор Шәрык клубында, бертуган Кәримовлар йортында, Ахунд Абызовның өендә булалар. Бу мәҗлесләрнең һәммәсендә губернатор белән Н.Катанов та катнаша.

Паша Казанда булган шул өч көн дәвамында, кунакханә каршысы һәрвакыт халык белән тулып тора. Кунакханәгә кереп чыкканда гына булса да, Пашаны күреп калу нияте белән, руслардан да, мөселманнардан да бик күп кеше килә. Кунакханәгә Паша белән күрешергә килүче халык арасында бер төркем яшь кыз укучылар да була [20].

Паша 16 апрель көнне оештырылган кичке аш мәҗлесеннән кунакханәгә кайтканнан соң, Катановка түбәндәге мәсьәләләр буенча мәгълүмат алырга теләве турында белдерә: 1) татар телендә һәм сөйләшләрендә сөйләшүче Идел һәм Себер төркиләренең саны, диннәре һәм яшәгән җирләре; 2) университетның 4 факультетының, бигрәк тә көнчыгыш телләре факультетының дәрес программалары; 3) Казан, Кырым һәм Алтын Урда ханнарының Чыңгыз хан белән булган гаилә бәйләнешләре; 4) татар теле сөйләшләрендәге охшашлыклар һәм аерымлыклар. Н.Катанов Пашаның бу сорауларына җавапны иртәгәсе көнгә җитештерергә сүз бирә. Тик җыелачак документларның күбесе рус телендә булачагын да белдерә. Паша Истанбулдагы секретарьларының бик яхшы русча белүләрен һәм алардан тәрҗемә иттерәчәген әйтә. 16 апрель иртән Н.Катанов белән Н.Ашмарин

кунакханәгә киләләр. Катанов Пашага «Чыңгыз хан һәм улы Җуҗинең шәҗәрәсе», «Иске һәм яңа татар сөйләшләренең чагыштырма фонетик таблицасы», «Идел болгарларының эпиграфик истәлекләре», «Казан университетының 1909-1910 елгы академик белешмәлеге» кебек берничә хезмәт бүләк итә. «Бәянелхак» газетасының редакторы Әхмәтҗан Сәйдәшев тә Пашага Гайнетдин Әхмәровның «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» исемле әсәрләрен бүләк итеп бирә.

Хилми Пашаның Казанга килүе, чынлап та, зур вакыйга булган, халык атналар буе шул хакта сөйләшкән. Казан, тарихында беренче тапкыр, Госманлы пашасын кунак иткән.

17 апрель көнне көндез Паша Казаннан Самарага юл ала. Пашаны озатырга килгән кешеләр арасында губернатор, шәһәр башлыгы, жандарм идарәсе башлыгы, полиция идарәсе башлыгы, матбугат вәкилләре, шәһәр имамнары, татар халкының алдынгы кешеләре була. Алда да әйтеп үтелгәнчә, Пашаның Казанга килү вакыты билгеле булмаганлыктан, пристаньга аны каршыларга бик аз кеше килгән булса, аны озатырга килгән кешеләрнең саны меңнән артып китә.

Хилми Паша Самарада Иванов кунакханәсенә урнаша, аңа өч бүлмәдән торган һәм шәрыкчә җиһазландырылган номер билгеләнгән була. Пашаны губернатор, полиция идарәсе башлыгы, жандарм офицеры, жандармнар һәм атлы казаклар белән каршы алалар [19: 3].

Хилми Паша Варшавада «Русское слово» газетасы хәбәрчесе белән әңгәмәсендә, үзенә күрсәтелгән игътибар һәм хөрмәттән бик канәгать калуын, ун көнгә планлаштырылган Русия сәяхәтен көчкә бер айда тәмамлый алуын, бигрәк тә Казан мөселманнары тарафыннан күрсәтелгән олы хөрмәттән бик шат булуын белдерә. Моннан тыш, Русия мөселманнарының рус ватандашлары белән бер үк хокукларга ия булуларына бик сөенүен әйтә [16].

Паша берничә елдан бирле Европа сәяхәтенә чыгарга теләгәнлеге, әмма рәсми вазифалары сәбәпле моңа мөмкинлек таба алмаганлыгы, баш вәзирлектән киткәннән соң, бу мөмкинлек туганлыгы турында әйтә һәм моңарчы ишетеп кенә белгән Европаны үз күзләре белән күрүенә бик канәгать калуын белдерә. Русияне күреп тануның исә үзе өчен зарури эш булуын һәм бу сәбәпле Европа сәяхәте арасында Русияне дә күрергә теләгәнлеген әйтә. Русиянең Петербург һәм Мәскәү кебек әһәмиятле шәһәрләрен күргәннән соң, дин кардәшләре яшәгән җирләрне дә барып күрүне үзенең вазифасы итеп белүен һәм Русия мөселманнарының мәркәзе булган Казанга барырга дигән карарга килгәнлеген белдерә.

Хөсәен Хилми Пашага бу, гадәти Русия сәяхәте вакытында рәсми чакырылган дәүләт кешеләренә күрсәтелә торган олы хөрмәткә лаек була. Хилми Паша сәяхәтенең Русия мөселманнары өчен тагын бер әһәмиятле ягы – тарихта беренче тапкыр Госманлы пашасының үзләре белән күрешергә килүе, аларның хәл-әхвәлләре хакында белергә тырышуы. Русия мөселманнары моңа кадәр Госманлы илчеләре булган пашаларның исемнәрен газеталарда гына күрәләр иде. Мәсәлән, элеккеге илчеләрдән Шакир Паша, Пенза төбәгенә рус дусларының биләмәләренә ауга баргалый, ләкин Мәкәрҗә ярминкәсендә яки Казанда бер тапкыр да булмый. Шакир Пашадан соң озак еллар илчелектә эшләгән Хүснү Пашаның хәтта Петербургта да бер мөселман кешесе белән күрешкәнлеге турында хәбәр юк, шуңа күрә Хилми Пашаның сәяхәте Русия мөселманнарының игътибарын бик нык җәлеп иткән [21].

Мәхмүд Әсад әфәнде 1913 елның 13 июлендә Истанбулдан юлга чыгып, Одесса, Киев, Акмәчет (Симферополь), Бакчасарай, Севастополь, Ялта, Новороссийски, Царицын, Самара, Оренбург, Уфа, Казан, Түбән Новгород, Мәскәү, Петербург шәһәрләре кергән маршрут буенча озакка сузылган сәяхәтен тормышка ашыра. Финляндия, Швеция, Норвегия, Германия илләре аша Истанбулга кире кайта. Мәкаләбездә Мәхмүд Әсад әфәндενең югарыда күрсәтелгән юлының бары Русия бүлеменә, аның да Идел-Урал өлешенә тукталачакбыз. Шул чор татар матбугатында да нигездә Идел-Урал төбәгенә сәяхәт хәбәрләре һәм аның хакында мәкаләләр басылган.

Мәхмүд Әсад әфәнде сәяхәтенең максаты Русия һәм аеруча аның төньягында урнашкан төркиләр белән якыннан танышу була. Ул Истанбулдагы татар дуслары Йосыф Акчура, Габдеррәшит Ибраһим һәм чыгышы белән Троицкидан булган Әхмәт Таҗетдиннән төньяк төркиләре турында күп нәрсә ишетеп белә, шулай ук Русия мөселманнарының тормышы турында язмалар бирә торган «Тәгарүф-и мөслимин» («Мөселманнарны тану») журналы редколлегиясендә булганлыктан, төньяк төркиләрне чит-ят итеп тоймый. Сәяхәт итүне

бик яратып бетермәгән Госманлы дәүләт кешеләренә һәм зыялыларына юл күрсәтү аның икенче максаты була [6]. Бу турыда жандарм отчетларында да әйтелә. Аның Идел-Урал төбәгенә килүенең төп сәбәбе – төрекләрнең бу җирләргә сәяхәт итүләре өчен юл ачу, аларны төбәк белән таныштыру, монда яшәгән мөселманнарның Төркиягә һәм төрек халкына карата симпатиясен арттыру, кирәге чыкса, биредәге мөселманнардан ярдәм сорау. Яшьләр һәм сәүдәгәрләр арасында булырга тырышуы аларның милли рухларын өйрәнергә тырышу дип аңлаталар [22].

Сәяхәтен Кырымнан башлаган Мәхмүд Әсад әфәнде Төркиягә күчеп китәргә бик ашкынып торган Кырым татарларының киләчәген караңгы итеп күзаллый, чөнки мәдәни тормыш өчен ул чордагы Төркиягә караганда, Русия күп өлеш ышанычлырак ил була. Мөһаҗирләр үзләренең җәннәт кебек ватаннарын, җирләрен ташлап, Төркиядәге ут эченә барып кергәннәр, хәтта Анадолуда үзләренә бирелгән җирләрне ошатмаган мөһаҗирләрнең бер өлеше яңадан Кырымга кире кайтып киткән очраклар да булган. Мәхмүд Әсад әфәнде Кырымда чахотка һәм сифилис авыруларының бик җәелгән булуын тагын бер кимчелек төсендә билгеләп үтә. Аныңча, бу хәл милләтнең киләчәге өчен бик куркыныч. Моннан тыш, Кырым мөселманнары арасында фикер һәм гыйлем ияләренең аз булуы да Әсад әфәндене борчуга сала. Шул ук вакытта, бу халыкның уяныр өчен тырышуын да якыннан күрә. Кырым мөселманнарына онытылмаслык хезмәт күрсәткән кешеләрнең иң алдынгысы итеп Исмәгыйль Гаспралыны саный. Ул Кырымда Гаспралы җитәкчелегендә барлыкка килгән алгарыш ташкынының төрки дөньяның мәдәният һәм әдәбият тарихында әһәмиятле урын алачагын ассызыклый. Газета хәбәрчеләре белән булган әңгәмәләрендә Гаспралы турында: «Исмәгыйльл бәй Гаспринский утыз елдан бирле ватандашларының матди һәм рухи тәрәккыйләре өчен тормышын багышлаган, иң җайсыз, уңайсыз вәзгыятьтә булса да, әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешкән. Исеме мәңгегә хөрмәт белән искә алыначак» – ди [23]. Шулай ук аны « төрки дөньяның гына түгел, бәлки бөтен Ислам дөньясының нурлы йолдызы» дип атый [24].

«Тәрҗеман» газетасы Мәхмүд Әсад әфәнденең Кырым сәяхәтен бөтенләй игътибарсыз калдырган, күрешүләре турында хәбәрләр бирмәгән. Бары тик эчке хәбәрләр бүлегендә, кыска гына язмалар белән Мәхмүд Әсад әфәнденең билгеле бер вакыттан бирле Русия буйлап сәяхәт итүен укучыларына җиткергән. Бакчасарайга кадәр килгән бу мәшһүр сәяхәтче белән Гаспралының күрешмәү сәбәбләре түбәндәгеләр булырга мөмкин: 1) Гаспралы бу вакытта Бакчасарайда булмаган; 2) Мәхмүд Әсад әфәнденең 1899 елда Измирдә басылган «Тагаддүд-и зәүҗат» («Күп хатынлылык») әсәренең ахырында үзенең күп хатынлыкка каршы фикерләрен кире кагарга тырышуы өчен Гаспралы күрешергә теләмәгән. Соңгысы дөреслеккә туры килергә охшый, чөнки әгәр мондый ачуы юк икән, Гаспыралы Бакчасарайда булмаса да, «Тәрҗеман» Мәхмүд Әсад әфәнденең Кырым сәяхәтенә тиешле игътибарны күрсәтер иде. Бары тик Мәхмүд Әсад әфәнденең Казан һәм Оренбург газеталары өчен биргән әңгәмәләрендә Кырымнан Төркиягә күчеп китүләрне кырыс тәнкыйть итүеннән һәм кайбер әңгәмәләрендә Исмәгыйль Гаспралыны мактап телгә алуыннан соң гына, «Тәрҗеман» Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәте турында тулы мәгълүмат бирә башлаган. Моннан тыш, Мәхмүд Әсад әфәнденең, Истанбулга кайтканнан соң, «Сабах» («Иртә») газетасы хәбәрчесе Бәдри Кәмаль бәй белән әңгәмәсе бирелгән мәкаләсендә, Кырым татарларының күчеп килүләре мәсьәләсен күтәрү, Гаспралыга уңай бәя бирү сәбәпле, аннан күчермә алып, үз битләрендә бастырып чыгарган. «Тәрҗеман» газетасы Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәтенә шундый бәя бирә: «Үткән җәй нур чәчеп торучы планета кебек, көньякта барлыкка килеп бик ашыгып Русиядә сәяхәт итүче, төньяк көнчыгышта Уфа һәм Казан якларына, аннан төньяк-көнбатышта Финляндия эчләренә кадәр нур чәчеп йөрүче мөхтәрәм Мәхмүд Әсад әфәнде бу сәяхәтен бер рисалә (брошюра) итеп бастырса, бик файдалы булачак. Русиядә үзе күрешкән мөселманнарга биргән дини һәм мәдәни мәгълүматы биредә зур тәэсир калдырган булса, Русия һәм андагы мөселманнар турында алып кайткан фикерләре, белемнәре дә анда файда китерәсенә шик юк» [25].

Мәхмүд Әсад Одесса, Киев, Акмәчет, Бакчасарай, Севастополь, Ялта, Новороссийск, Царицын һәм Самарада ике атналап сәяхәт иткәннән соң, 29 июль иртән Оренбургка барып җитә. Русча белмәгәнгә, юлларда шактый мәшәкать чигә, чөнки чит телләрдән бары тик французча һәм инглизчәне белә, ә Русиянең

эчке төбәкләрендә бу телләрне белүчеләрнең саны бик аз була. Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта иң башта Фатих Кәрими белән бергә Хөсәения мәдрәсәсен барып күрә. Ул көн, мәдрәсәнең финанс эшләре белән идарә итүче комитеты әгъзаларының җыелыш көне була, шул сәбәпле Мәхмүд Әсад әфәнде аларның һәммәсе белән күрешә. Мәдрәсәдән соң, «Шура» журналы мөхәррире Ризаэтдин Фәхретдин белән очраша. Ике галим фаиз (процентлар), риба (тавар алмашуда процентның бер төре), банклар, страхование мәсьәләләре кебек шул чор мөселманнарының зиһеннәренә тынычлык бирмәгән мәсьәләләр турында сөйләшәләр. Мәхмүд Әсад әфәнде Риза Фәхретдингә түбәндәге фикерләрен җиткерә: «Дин реформасы турында язган фикерләрегез белән без тулысынча килешәбез. Диннең җанлы булуы һәм шул динне тотучыларны рухландыру өчен аның һәрвакыт акыл һәм фикер белән бергә булуы кирәк. Дин ислахына каршы килү Исламны һәм мөселманнарны юк итәргә теләү белән бер. Бу эш исә дингә карата зур җинаять. Ләкин без реформалар адым-адым ясалырга тиеш дип барабыз. Халыкка барын бергә аңлату читен, алар кайчак, булмас хәл дип куркалар, һәр нәрсәнең җае белән эшләнүе яхшы» [26: 3-4].

Мәхмүд Әсад әфәнденең Оренбургта күрергә теләгән урыннарыннан тагын берсе – кадимчеләрнең иң әһәмиятле матбугат органы «Дин вә мәгыйшәт» журналы була. Фатих Кәрими кунакны «Дин вә мәгыйшәт» журналына алып баруының сәбәбен «Шәригать таләп итәбез диючеләрнең саны Истанбулда да аз түгел. Әмма бездәгеләрне дә күреп китсен, дидем» дип аңлата. «Дин вә мәгыйшәт» журналын бастырып чыгаручы Мөхәммәтвәли әфәнде Мәдинәдә белем алган һәм берара Истанбулда да яшәгән, шунлыктан төрек телен бик яхшы белә. Ул Мәхмүд Әсад әфәнде белән төрекчә сөйләшә. Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургка килгәнче, «Дин вә мәгыйшәт» журналы аның «Тагаддүд-ү зәүҗат» исемле әсәреннән өзекләр китереп, үзе турында «… җәнаплары Төркиянең могътәбәр вә мокътәдир галимнәреннән булып, «Хокук-у дүвәл», «Дин-и ислам», «Икътисад вә тарих-и дин-и ислам» вә «Тагаддүд-ү зәүҗат» намында әсәрләре бардыр» [27: 491-492] дип язып, мактаулар яудыра. Ләкин Мәхмүд Әсад әфәнденең «Вакыт» газетасында Фатих Кәрими белән әңгәмәсе басыла башлаганнан соң, аны динне бозуда гаепләп, «Вакыт» газетасы язып чыккан кадәр үк зур галим түгеллеген әйтеп яза башлый [28: 517-521].

Мәхмүд Әсад әфәнде Фатих Кәрими белән булган әңгәмәсендә дин реформасын кирәкле дип таный, тик аны динне үзгәртү, азайту яки күбәйтү рәвешендә күзалламый, диннең хөкем һәм мөгамәлә системасын заман таләпләренә туры китерү кирәклеген ассызыклый. Мәхмүд Әсад әфәнде фикеренчә, «диннең хөкем һәм мөгамәлә системасын заман таләпләренә туры китермәү, илаһи хикмәткә каршы килү була, чөнки Җәнаб-е хак динне кешелек сәгадәте өчен биргән. Әгәр инсаннар дин ярдәме белән бәхетле һәм канәгать була алмасалар, ул диннең изгелеге калмас иде» [26: 3].

Бу чорда Русия мөселманнары арасында ике фикер агымы була: беренчесе, һәртөрле яңалыкка дошман булган һәм мөселманлыкны шул хәлендә сакларга теләгән консерваторлар; икенчесе исә, исламның иҗтимагый, икътисадый һәм дини якларын ислах итүне таләп иткән тәрәккыйпәрвәрләр, ягъни прогресс яклылар. «Дин вә мәгыйшәт» журналы беренче агымның иң көчле яклаучысы була. Бу журнал мөселманлыкның башына килгән бөтен бәхетсезлекләрнең сәбәбен мөселманнарның дини тормыш белән яшәмәүләрендә, ураза, намаз һәм хаҗга тиешле игътибарны бирмәүләрендә, хатыннарның ачык йөрүләрендә, гореф-гадәтләрнең бозылуында күрә. Икенче агымның иң алдынгы шәхесе Муса Җаруллаһ Бигиев була. Ул исә бу бәхетсезлекләрнең нигезен Коръәнне ялгыш аңлауда, тәфсир итә белмәүдә күрә. Элекке заманнарда ябып куелган иҗтиһад ишекләренең мөселманнар өчен ачылуын һәм Коръәнне турыдан-туры аңлау хокукының бирелүен таләп итә.

Мәхмүд Әсад әфәнденең Оренбургтан башланган Идел-Урал сәяхәте көннәрендә телләрдән төшмәгән, шул чор татар матбугатында да бик киң чагылыш тапкан мөһим мәсьәләләрнең берсе – тел мәсьәләсе була. Фатих Кәриминең бу хосуста: «Русиядәге татар, кыргыз, сарт, үзбәк кебек төрле исемнәр белән аталып йөртелә торган төрки кавемнәр, телләре һәм әдәбиятлары берләшеп, бер-берләрен аңлый алачак бер милләт хәленә килә алырлармы?» дигән соравына Мәхмүд Әсад әфәнде шул рәвешле җавап бирә: «Сезнең кулыгызда, ягъни бүгенге зыялыларыгыз һәм фикер ияләрегез шулай булсын дип теләсәләр, бу юлда хезмәт итсәләр, шөбһәсез, бу эш булыр» [26: 3-4]. Петербургта вакытта да, бу

сорау калкып чыга, «Мир ислама» журналы мөхәрриренең, төрле төрки телләрне берләштереп гомуми төрки тел һәм әдәбият барлыкка китерергә мөмкинме, дигән соравына: «Мондый гомуми төрки әдәбият барлыкка килү бик теләп, көтеп алынган хәл булыр иде. Илле миллионлык халыкның уртак әдәбияты барлыкка килү мәдәният дөньясы өчен бик мөһим һәм файдалы булачак, чөнки һәр милләт гомуми мәдәнияткә азмы-күпме файда китерә. Ләкин тар даирәләрдә калган мәхәлли сөйләм телләреннән мондый файда килү ихтималы юк» [29: 2-3], – дип җавап бирә. Мөхәррирнең: «Кырымда әдәби телнең госманлы теленә якыная баруы, аеруча Исмәгыйль Гаспралы бәйнең тырышлыгы белән утыз елдан бирле бу юлда мөһим үзгәрешләр барлыкка килүе инкяр ителә алмас. Кавказларда да моңа охшаш агым бар, Казан тарафларында да шундый ук хәл барлыкка килерме?» рәвешендәге икенче соравына исә, шул җавапны бирә: «Бу мәсьәлә бүгенге көндә дә Русия мөселманнары арасында бәхәс тудырган мөһим мәсьәлә булып тора. Бу юнәлештә ике агым бар: беренчесе, һәр тирәлекнең хосусый әдәбиятын алга җибәрү; икенчесе, төрки дөнья өчен уртак әдәбият барлыкка китерү. Хосусый әдәбиятларны үстерү бөтен тирәлекләрдә фикер ияләренең халык белән якынаюын, берләшүен җиңеләйтер иде. Тел үзгәртү белән шөгыльләнелсә, бу якынаю, берләшү беразга кыенлашыр. Тик тел аерымлыкларының – бер җирдә язылган нәрсәнең башка җирдә аңлашылып җитмәвенең – бер тирәлекне икенчесенә карата чит-ят итеп калдырганлыгы да инкяр ителә алмас. Гомуми бер әдәбият тәшкил итү тарафтарлары бу сәбәпне алга сөрәләр. Аларның җиңеп чыгачаклары мөмкинрәк булып күренә» [30: 477-478].

Оренбург мөселманнары Уфаның алдынгы кешеләренә телефоннан Мәхмүд Әсад әфәнденең Уфага киләчәген хәбәр итәләр. 31 июль көнне иртән Уфа вокзалында мөселманнар кунакны хөрмәт белән каршы алалар. Алар арасында Уфаның мәшһүр тарихчы һәм казый Хәсән Гата Габәши, Ахунд Җиһангир Абызгилдин, Нәҗип Хәкимов, Хәсән Кәримов, Салих Хәбиров кебек алдынгы шәхесләре була [30: 471-472].

Мәхмүд Әсад әфәнде Уфадагы сәяхәтен казый Хәсәнгата Габәши белән бергә Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының мөфтие Мөхәммәдъяр Солтанов белән күрешүдән башлый. Аннан соң беренче мәхәллә мәчетен барып күрә, Госмания, Галия, Хөсәения, Хәкимия мәчет һәм мәдрәсәләрендә була, соңыннан губернатор белән күрешә. Губернатор Мәхмүд Әсад әфәнде белән бер сәгатьләп сөйләшеп утырганнан соң, бергә шәһәр музееи барып карыйлар. Кичен губернатор һәм полиция кешеләре, Уфа мөселманнары Мәхмүд Әсад әфәндене озатып калалар. Ул пароход белән Казанга китә [31: 3]. Шәһәрдә моннан егерме ел элек бер мәчет кенә булып, бу көннәрдә исә инде егерме биш мәчет һәм мәдрәсәнең эшләве Мәхмүд Әсад әфәндегә Уфада иң тәэсир иткән нәрсә була. Бу хәл, аның карашынча, Уфа мөселманнарының алга баруын дәлилли торган төп күрсәткеч. Мәхмүд Әсад әфәндегә үзе карап йөргән Галия, Госмания, Хөсәения мәдрәсәләренең дәрес программалары һәм мөгаллимнәренең дәрәҗәсе дә бик көчле тәэсир итә.

Мәхмүд Әсад әфәнде төньяк төркиләрендәге мәдәният хәрәкәтенең чишмә башы итеп Казанны саный, чөнки үзе күргән Самара, Оренбург, Уфа, Түбән Новгород, Мәскәү һәм Петербург шәһәрләрендәге сәүдәгәр һәм мөгаллимнәрнең Казан белән мөнәсәбәттә булуларын күрә, аңлый. Шәһәрдә бер генә көнгә тукталса да, мөһим тәэссоратлар ала. Көн буе газета хәбәрчеләре белән йөргәнгә, мөгаен, аның бөтен сөйләшүләре матбугатта чагылыш тапкандыр.

Мәхмүд Әсад әфәнде 3 августта Казанга килә. Аны каршыларга килгән кешеләр арасында полиция идарәсе башлыгының ярдәмчесе Задановский, мөселманнардан Шәһәр Шәрәф, Ахунд Салихҗан Галиевнең улы, Мөхәммәтҗан Кәримов һәм Зәкәрия Садретдиновлар була. Шул көнне үк Казанда чыга торган «Кояш» газетасының мөхәррире Зәкәрия Садретдинов белән шәһәрнең истәлекле урыннарын, төрле газеталарның редакцияләрен карап йөри. «Кояш» газетасы язучысы Фатих Әмирхан белән ике сәгатькә якын сөйләшеп утыра, төрки һәм ислам дөньясының мәсьәләләре турында фикерләрен белдерә. Мәхмүд Әсад әфәндене Русия сәяхәте вакытында барыннан да элек илдәге тәртип, рус халкының әдәпле мөгамәләсе, төньяк төркиләрнең тәрәккый күренешләре, кунакчыллыклары тәэсирләндерә [24: 3].

Шул чорның татар журналистларын борчыган мәсьәләләрнең берсе – төрек матбугатында төрекләрнең милли тормышы белән бәйле хәбәрләргә урын бирелмәве. Алар: «Госманлы төрекләре тормышына караган

мәсьәләләрдә ихтыяҗ туганда төрек газеталарыннан түгел, рус газеталарыннан файдаланырга мәҗбүрбез», – дип, шикаятьләрен белдерәләр. Мәхмүд Әсад әфәнде фикеренчә, төрек газеталарының халык тормышына аз әһәмият бирүләренең ике сәбәбе бар: 1) госманлыда Европага иярү бик көчле, ил өчен әһәмияте булмаган мәсьәләләрне Европа газеталарына карап әһәмиятле итәләр, ил өчен әһәмиятле булганга, Европа газеталарында берәр ишарә күрмәсәләр, аларга игътибар итмиләр; 2) милли мәсьәләләр турында баш авырттырып мәкалә әзерләгәнче, Европа газеталарыннан алынган тәрҗемәләр белән газета битләрен тутыруны җиңелрәк саныйлар.

Рамазан ае булганлыктан, озын көннәрдә ураза турында да сүз кузгатыла. Казан кешеләре Мәхмүд Әсад әфәндегә моның белән бәйле шул сүзләрне сөйлиләр: «…мәгълүмегез, бүгенге көндә мәмләкәтебездә урак һәм сука вакыты, авыл халкының бары да басуда, эшнең авырлыгы, көннең озын һәм эссе булуы алар өчен бик кыен, тирә-юньнән килгән хәбәрләргә караганда, авырып китүчеләр дә бар». Мәхмүд Әсад әфәнде бу мәсьәләгә карата «Динебезне заман һәм урын үзенчәлекләренә карап ислах итү – бурычыбыз. Ислам дине – кыяматкә кадәр мәңге калачак дин. Шулай булгач, ни өчен заман һәм урынга карап үзгәреш кертү мөмкин булмасын? Үзгәреш керергә тиешле нәрсә – хөкемнәрдер, хөкемнәр исә, яшәлгән вакыт һәм җиргә бәйле рәвештә үзгәреш кичерер» дигән фикерен әйтә. Мәхмүд Әсад әфәнде Муса Җаруллаһның китапларын яратып укуын, Бигинең Исламда камиллеккә хезмәт итүен, Петербургка баргач, хөрмәт белән кулын үбәчәген әйтә [32: 2].

Мәхмүд Әсад әфәнде 6 август көнне Мәскәүгә килеп җитә. Станциядә аны беренче мәхәллә имамы Абдулла әфәнде һәм башка мөселманнар каршылый. Кунакханәгә урнашканнан соң, янына юлдаш итеп билгеләнгән Абдулла Дәвишов белән көн буе шәһәрнең истәлекле урыннарында йөриләр. Кичен мөселман җәмәгате кунак хөрмәтенә аш мәҗлесе оештыра. Иртәгесе көн беренче мәхәллә имамы Абдулла әфәнде белән бергә шәһәрнең сәүдә үзәкләрен һәм музейларын карыйлар. Кичен шәһәр байларыннан Әмруллаһ әфәнде кичке аш мәҗлесенә чакырып ала. Икенче көнне шәһәрнең алдынгы кешеләреннән торган бер төркем аны Петербургка озатып кала [33: 3-4].

Мәхмүд Әсад әфәнде Петербургта Төркия илчесе Тархан Паша белән күрешә, озак кына сөйләшеп утыралар, кичен илче кунак хөрмәтенә аш мәҗлесе оештыра. Әсад әфәнде Петербургта өч көн була. Муса Җаруллаһ Бигиев юлдашлыгында шәһәрнең зур китапханә һәм музейларын, сарайларын һәм Петербург мәчетен карый. Барган җирләрендә дәүләт кешеләре үзенә зур хөрмәт күрсәтәләр. Мәхмүд Әсад әфәнденең, Петербург сәяхәтенең башыннан ахырына кадәр үзенә юлдашлык иткән Муса Җаруллаһ Бигиев белән сәгатьләр буе дини мәсьәләләр, бигрәк тә Аллаһының рәхимлелеге турында сөйләшүләре билгеле булса да, Муса Җаруллаһ бу хакта үзе берни дә язып калдырмаган [6: 2-3].

Мәхмүд Әсад әфәнденең Русиягә килүе, Бакчасарай, Оренбург, Уфа, Казан кебек мөселман мәркәзләрендә гизүе Русия мөселманнары өчен гаять зур вакыйга була. Русия мөселманнары аны һәр җирдә олы хөрмәт күрсәтеп каршылыйлар. Исеме матбугат битләрендә бик еш күренгән бу галимнең Петербургка килгәнен белеп алган «Мир Ислама» журналы хезмәткәрләре аның белән булган бик озын әңгәмәне бастыра. 1913 елның 11 августында Петербургта «Франция» кунакханәсендә күрешеп корылган әңгәмәнең кереш өлешендә хәбәрче Муса Җаруллаһ Бигиев белән Мәхмүд Әсад әфәндене чагыштыра. Муса Җаруллаһ Бигиевнең дин ислахы турында бик күп язуын, озын фикерләүләргә кереп китүен, кайчакларда дин хокукы һәм дини ышанулар мәсьәләләренә кереп чумуын; ә шул вакытта Мәхмүд Әсад әфәнденең дәрес китапларыннан, кайбер гыйльми әсәрләр һәм тәрҗемәләрдән башка берни язмавын белдереп, аның Исламның ышану һәм гыйбадәт кылу мәсьәләләре белән бик артык мавыкмыйча, турыдан-туры максатка, тормышка һәм көнкүрешкә караган мәсьәләләрне гыйльми яссылыкта аңлатырга тырышуын билгеләп үтә, бигрәк тә канун әзерләү юлы белән бу мәсьәләләрне чынбарлыкта, эштә хәл итәргә тырышуын ассызыклый. Игътибарны аеруча җәлеп иткән нәрсә: мәсьәләләрне гамәлдә, чынбарлыкта хәл итүдә Мәхмүд Әсад әфәнде Муса Җаруллаһ әфәндедән күпкә алда, аңа караганда күпкә батыррак эш итә. Чөнки Муса әфәнде мәсьәләләрне шәригатькә яраклаштырырга тели: боларга һәрвакыт озаклап туктала. Мәхмүд Әсад әфәнде исә, кирәкле реформаны үткәрү өчен, аны шәригатькә ничек

яраклаштырырга икән, дип баш ватмый, кирәклеген дә күрми. Мәхмүд Әсад әфәнде хәзерге заман дин галиме күпчелеге кебек назарият (теория) һәм фаразият (күзаллау) тарафдары түгел. Мәсьәләләргә турыдан һәм төз торып карый алуы аның иң мөһим сыйфатларыннан берсе.

Мәхмүд Әсад әфәнденең хәзерге бөтен максаты Төркиянең икътисади хәлен яхшырту була. Һичшиксез, аның бу юлдагы хезмәтеннән мөселманнарга килгән файда, Сәед Җәмалетдин Әфганинең ислам берлеге фикерен җәелдерергә һәм Муса Җаруллаһ Бигиевнең динне ислах итәргә тырышуларыннан килгән файдадан күпкә артык дип билгели.

Шул вакытларда шәйхелислам, Муса Җаруллаһ Бигиевнең кайбер әсәрләрен тыйган була һәм ул да татар журналистларын бу турыда Мәхмүд Әсад әфәндегә сорау бирергә этәрә[5]. Мәхмүд Әсад әфәнде шундый җаваплар бирә: «Ислам галәменең һәр почмагында әле һаман «Ишми»ләр хөкем итә. Ишми әфәнденең китапларын гарәпчә язганлыгын ишетеп бик сөендем, чөнки бу сәбәпле гарәп телен белмәгән татарлар аның зарарлы сүзләрен укып агуланудан котылып калалар. Муса әфәнде «Вакыт» газетасында үзе дә язып бастырды: Шәйхелисламның фәтвасы, төрки дөньяга Муса әфәнденең китапларын танытты. Бөтен кеше сатып алыр өчен атылды, мин дә шуларның берсе» [35: 2].

Төньяк төркиләр арасындагы сәяхәтенең тәэссораты турындагы сорауга исә: «Бик яхшы, бик канәгать калдым, төньяк төркиләрендәге тәрәккыятьне күреп сөендем [6: 2-3]. Русиянең зур шәһәрләренең барысында да диярлек вокзаллардагы буфетлар касыйм татарлары кулында, мин булган бөтен шәһәрләрдә татар сәүдәгәрләре һәм кибетчеләре бик күп. Оренбург, Самара, Уфа һәм Казанда дин, икътисад, сәүдә өлкәсендә алдынгы, көчле ислам җәмәгате белән очраштым. Казан һәм аның әйләнәсе Кытайга кадәр сузылган җирләрдә яшәүче ислам әһелләре мәгърифәт нуры чәчә. Бөтен төбәкләрдә Казан һәм аның тирә-юненнән чыккан галимнәр, мөгаллимнәр һәм сәүдәгәрләрне очратасың. Һәр җирдә халыкта тәрәккыйгә зур омтылыш һәм бик җитди тырышлык күренә. Казан һәм аның әйләнә-тирәсе – ислам дөньясының иң алга киткән мәдәни үзәге. Ләкин, кызганыч, моның әһәмиятен без бүгенгә кадәр тиешенчә аңлый алмаганбыз. Төньяк төркиләре сәүдә һәм сәнәгатьтә көньяк төркиләренә караганда шактый алда баралар. Бигрәк тә Казан мөселманнары! Безнең Истанбулда мөселманнар арасында бик бай кеше яисә фирмалар табу кыен, ә Казанда исә берничә миллионер бар!» [36].

Истанбулда чыга торган «Сабах» газетасы Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәте турындагы хәбәрләрне татар газеталарыннан алып, укучыларына җиткерә. Мәшһүр татар язучысы Фатих Әмирхан белән әңгәмәсендә, язучының Госманлы матбугатының милли мәсьәләләргә бик әһәмият бирмәве турындагы фикерен Әсад әфәнденең дә уртаклашуы «Сабах» газетасы тарафыннан тәнкыйтьләнә, әлеге әңгәмәгә биргән җавапларында бу хәлнең дөреслеккә туры килмәвен исбатларга тырышалар [37]. «Сабах» газетасы, Госманлы матбугатының Европа газеталарыннан бик күп күчереп басуын һәм моның матбугат дөньясында гадәти хәл булуын, күчермәләрсез матбугатның дөнья хәбәрләреннән ярлы булып калачагын тәкърарлый.

Татар матбугаты исә, Госманлы матбугатының Русиядә яшәгән 20 миллионлык халык массасына игътибарсыз калуы, Казан һәм аның тирә-юнендә Госманлы матбугатын алдыручы кешеләрнең саны күп булуга карамастан, Истанбул зыялылары арасында татар матбугаты алдыручы юк дәрәҗәсендә аз булуы турында яза һәм бу чынбарлыкка туры килә. Бүген Төркия китапханәләрендә ул чор матбугатына караган нөсхәләр бик аз санда һәм бу Госманлы зыялыларының татар матбугаты белән кызыксынмаганлыкларын бик ачык күрсәтә [38].

Истанбулда чыккан «Сабах» газетасы мөхәррире Бәдри Кәмаль бәй, Мәхмүд Әсад әфәнденең Русия сәяхәтен түбәндәгечә бәяли: «Мәхмүд Әсад әфәнденең Русиянең Европа өлешендә урнашкан һәм мөселманннар яши торган шәһәрләренә сәяхәте, ике илдә яшәгән мөселманнар арасындагы дуслык-туганлык җәһәтеннән генә түгел, бәлки Госманлы – Рус сәяси һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләре җәһәтеннән дә әһәмиятле булды. Инсаннарның табигате шундый: кайчакта иң якын җирләрне, иң җиңел эшләрне оныталар да ерак җирләр белән бәйләнешле, ихтимал, мәнфәгатьләренә

[5] Муса Җаруллаһ Бигиевнең шәйхелислам тарафыннан тыелган әсәрләре шулар: «Рәхмәт-и иляһиия борханлары», «Инсаннарның акыйдә-и иляһияләренә бер назар», «Озын көннәрдә ураза», «Каваид-е фыкһия». Бу турыда тагын да киң мәгълүмат өчен карагыз: [34: 13-16].

катнашы да бик булмаган эшләр белән шөгыльләнәләр. Заманында, японнар ислам дине кабул итәчәкләр дигән әкиятләр белән газеталарыбыз битләрен тутырган бер вакытта, Русиядә яшәгән миллионнарча ислам әһелләренең ни эшләгәнен,ниләр барлыкка китергәнен, ихтыяҗлары нидән гыйбарәт булуын беркем хәтеренә дә китереп карамады. Югыйсә, Русия мөселманнары белән төрекләр арасында дин уртаклыгыннан башка, кардәшлек һәм тел якынлыгы да бар. Русиядәге мөселманнар да төрек. Аларның алгарышы төрекләрнең дә тәрәккые дигән сүз. Тормышлары да – төрек тормышының бер өлеше. Шуңа күрә Госманлы мохитендә аларның тормышына башка җирләрнең иҗтимагый һәм әдәби тормышыннан артыграк әһәмият бирергә кирәк. Чөнки Русиядәге дин кардәшләребезнең мәдәни хәле төрки дөньяның киләчәгенә иң мөһим мөнәсәбәтләр белән бәйле. Бу хакыйкатьләр Госманлы матбугаты тарафыннан соңгы вакытларда игътибарга алынып, газеталарыбыз Русиядәге ислам әһелләре хакында аз булса да мәгълүмат бирә башладылар. Иң күп таләп ителәчәк нәрсәләрдән берсе – Русиянең мөселманнар яшәгән шәһәрләреннән Төркиягә, Төркиядән Русиягә сәяхәт төркемнәре оештыру. Мондый сәяхәтләр төрки дөньяның ике әһәмиятле бүлеме арасында мәдәни, иҗтимагый бәйләнешләрне көчәйтәчәк» [39].

Мәхмүд Әсад әфәнде Русия хөкүмәте тарафыннан үзенә күрсәтелгән нәзакәт һәм илтифаттан канәгать кала. Аны барган бөтен җирдә хөкүмәт гаскәриләр, полиция, жандармнар катнашында рәсми каршы ала. Рәсми даирәләргә баргач, бик зур илтифат күрә, ә мөселманнар тарафыннан күрсәтелгән илтифат һәм хөрмәтне тасвир итәр өчен сүзләр таба алмый. Дөресе генә, диндәш һәм кардәш халыктан булган берәүгә бу дәрәҗәдә сый-хөрмәт күрсәтәчәкләрен уйламаган була. Бу самими илтифатларына олы рәхмәтен белдерә… [39].

Русия мөселманнарының иҗтимагый хәлләрен, сәүдә, сәнәгать, мәгариф кебек өлкәләрдәге тәрәккыйләренең дәрәҗәсен күреп бик сөенә. Мөселманнарда фанатизмның булмавын, киресенчә, чын мәгънәсендә ныклы дин һәм миллият барлыгын күрә [25].

Русия мөселманнарының Госманлы – Рус мөнәсәбәте турындагы фикерләре: Русия мөселманнарының самими теләкләре – Төркия белән Русия арасында чын дуслыкның булуы, чөнки мөселманнар Төркияне һәм төрки дөньяны бик үз күрәләр. Төркия белән мөмкин булган кадәр тыгыз фикри, мәдәни, иҗтимагый мөнәсәбәттә булырга телиләр. Дин, кардәшлек, тел бәйләнешләренең әһәмиятенә карасаң, бу теләк бик тә табигый. Русия дәүләте белән Госманлы арасындагы мөнәсәбәтләр никадәр самими булса, үзләре белән төрекләр арасындагы мөнәсәбәт тә шул нисбәттә иркен үсеш алачагын уйлыйлар. Шуның өчен ике дәүләтнең үзара дус булуын телиләр. Заманалар шактый үзгәрү сәбәпле, русларда да матур мөнәсәбәт гамәлләре күренү, элегрәк кылынган гамәлләрнең инде хәзер әһәмияте азлыгы турында әйтелә.

«Мир Ислама» журналы мөхәрриренең пантюркизм, панисламизм, мөселманнар арасында консерваторлык һәм прогресс яклылык турындагы сорауларына Мәхмүд Әсад әфәнде шундый җавап бирә: «Панисламизмны, пантюркизмны сәяси мәгънәсе белән уйлап карыйк, ягъни, бөтен дөнья мөселманнары яки бөтен дөнья төркиләре үзләре өчен бер сәяси хөкүмәт төзергә телиләрме? дип сорасагыз, бу – катгый рәвештә юк һәм моның булуы мөмкин дә түгел. Мондый хыяллар белән маташу мөселманнарның һәм төркиләрнең үзләре өчен һәм аеруча Төркия өчен зарарлы. Әгәр, мөселманнар һәм төркиләр үз араларында гыйльми, мәдәни һәм сәүдә өлкәсендә мөнәсәбәт корырга телиләрме? дип сорасагыз, әлбәттә телиләр. Моннан беркемгә дә зарар юк, булса тик файда гына булачак. Гомумән мөселманнар арасында мондый кардәшлек элеккеге заманнардан бирле бар һәм дәвам да итәчәк [25].

«Мир Ислама» журналы мөхәррире Мәхмүд Әсад әфәндедән панисламизм турында нәрсә уйлавын сорый. Мәхмүд Әсад әфәнде бу фикернең хөкүмәт тарафыннан якланмавын, буш хыял гына булуын белдерә һәм бу фикернең христиан күршеләрне борчуга салудан башка бер эшкә дә ярамаганлыгын әйтә. Моңа каршы журналист, хөкүмәт газетасында басылган Шәхбәндәрзадә Хилми әфәнденең коткысына алайса нәрсә дияргә кирәк, дип сорау бирә. Мәхмүд Әсад әфәнде бу сорауга җавабында, Шәхбәндәрзадәнең хыяллар белән яшәүче бер язучы булуын, хыялый кешеләрнең һәр җирдә барлыгын, үзләре омтылган һәм язып бастырган хыяллары өчен бары тик үзләре генә җаваплы икәнлеген белдерә.

Хилми Пашаның Русия сәяхәте Госманлы – Рус мөнәсәбәтләре яхшы булган чорга туры килә. II Мәшрутият игъланы рус демократлары

тарафыннан зур канәгатьлек белән каршылана һәм йөзләрчә кеше бу вакыйгадан соң Истанбулга барып мәшрутият котлауларында катнаша. Бу кешеләр арасында Дума рәисе .... Гочков та бар. Йосыф Акчура мәшрутият игълан ителгәч, Мәскәүдә озак вакытлар Госманлының популярлык казанганлыгы турында яза [40].

Хилми Паша һәм Мәхмүд Әсад әфәнденең Идел-Урал сәяхәтләренең тагын бер әһәмиятле ягы – тәэсирле булу ягыннан аларның беренче һәм соңгы булулары. Идел-Уралга бу дәрәҗәдәге башка сәяхәт кылынмаган. Җәлал Нури Иләренең 1910, Әхмәт Җәүдәтнең 1914 еллардагы сәяхәтләре турында шул чор татар матбугатында бөтенләй диярлек хәбәр бирелмәгән, ә Хилми Паша һәм Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәтләренә мөселман матбугаты да, рус матбугаты да зур кызыксыну күрсәткән, һәм бу аңлашыла, чөнки Идел-Урал буена алардан элегрәк мондый зур дәрәҗәдә һичбер сәяхәт булмаган. Хилми Пашага күрсәтелгән игътибарны аның үз дәүләтендәге эш урыны, вазифасы, Мәхмүд Әсад әфәндегә күрсәтелгән илтифатны да үз дәүләтендә тоткан урыны һәм галимлегенә бәйләп аңлатырга мөмкин. Хилми Паша Русия мөселманнары арасында киң танылган шәхес булмый, шул сәбәпле аңа күрсәтелгән игътибарны «эш урынына» һәм димәк ки, Госманлы дәүләтенә булган игътибар дип бәяләү иң дөресе булыр. Ә инде Мәхмүд Әсад Әфәндене Идел-Урал буенда яшәгән зыялыларның күбесе танып белә. Аның «Ислам тарихы» исемле ике томлык әсәре татарчага тәрҗемә ителгән [41], «Тагаддүд-и зәүҗат» исемле әсәреннән дә кайбер бүлекләр «Шура» журналында басылып чыккан була [42]. Ул Русия мөселманнары тарафыннан Истанбулда чыгарган «Тәгариф-и мөслимин» журналына мәкаләләр дә язган. Истанбулга юлы төшкән күпчелек татар зыялылары аның белән күрешеп китә торган булалар [43].

Димәк, Хилми Паша һәм Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәтләре, бер яктан, Русия һәм Төркия дәүләтләре арасындагы мөнәсәбәтләр хакында мәгълүмат бирсә, икенче яктан тугандаш халыклар – Идел-Урал буе татарлары һәм төрекләр арасындагы рухи, иҗтимагый, дини бәйләнешләрне тирәнәйүгә, кан-кардәшлек һәм туганлык җепләрен ныгытуга хезмәт итә. Аннан тыш шушы сәяхәтләр уңаннан матбугатта басылган хәбәрләр һәм мәкаләләр укучыга шушы чорның мәдәни, рухи тормышы, татар һәм төрек халыкларының мәшһүр затлары хакында бай мәгълүмат бирә.

*Хилми Паша һәм Мәхмүд Әсад әфәнденең сәяхәтләре турында шул чор татар һәм рус матбугатында чыккан хәбәр һәм мәкаләләр:*

1. Хилми Паша мәдрәсә-и Мөхәммәдиядә // Бәянелхак. 1910. № 602. 18 апрель.
2. Хөсәен Хилми Пашаның Казанны зиярәте // Бәянелхак. 1910. № 603. 20 апрель.
3. Габдеррәшит Ибраһим. Дәврә-и галәм. Хөсәен Хилми Паша // Бәянелхак. 1910. № 618. 25 апрель.
4. Хилми Паша // Новое время 1910. № 12226. 26 март (8 апрель).
5. Хилми Паша в Петербурге // Новое время. 1910. № 12227. 26 март (9 апрель).
6. Петербург 5 апреля, Русско-турецкие отношения // Новое время. 1910. № 12237. 6 (19) апреля.
7. Гариф Кәрими. Хилми Паша Мәскәүдә // Вакыт. 1910. № 606. 17 апрель.
8. Хилми Паша хакында Казан халкы // Вакыт. 1910. № 608. 24 апрель.
9. Фатих Мортазин. Хилми Паша Самарада // Вакыт, 1910, № 609, 27 апрель.
10. Абдеррахман Мостафин. Хилми Паша мәҗлесендә // Вакыт. 1910. № 610. 29 апрель.
11. Хилми Паша вә Русия мөселманнары // Вакыт. 1910. № 611. 1 май.
12. Хилми Пашаның мәктүбе // Вакыт. 1910. № 624. 1 июнь.
13. Петербургта Хилми Паша хөрмәтенә зияфәт // Йолдыз. 1910. № 528. 15 апрель.
14. Хилми Паша Казанда // Йолдыз. 1910. № 529. 19 апрель.
15. Хилми Паша Мәдрәсә-и Мөхәммәдиядә // Йолдыз. 1910. № 530. 21 апрель.
16. Хилми Пашаның Казанга килеш хәтирәләре // Йолдыз. 1910. №530. 21 апрель.
17. Хилми Паша Самарада // Йолдыз. 1910. № 530. 21 апрель.
18. Хилми Паша Варшавада // Йолдыз. 1910. № 532. 27 апрель.
19. Хилми Паша шәрәфенә «Новое время» газетасының зияфәте// Нур. 1910. № 190. 8 апрель.
20. Хилми Пашаның «Новое время»ны зиярәте хакында // Йолдыз. 1910. №539. 13 май.
21. Җ.А. Хөсәен Хилми Паша Русиядә // Тәрҗеман. 1910. № 18. 30 апрель.
22. Хилми Паша // Новое время. 1910. № 12226. 26 март (8 апрель).
23. Хилми Паша в Петербурге // Новое время. 1910. № 12227. 26 март (9 апрель).
24. Петербург 5 апреля, Русско-турецкие отношения // Новое время. 1910. № 12237. 6 (19) апрель.
25. «Мир ислама» журналы вә Мәхмүд Әсад // Вакыт. 1913. № 1312. 4 октябрь.

26. Фатих Әмирхан. Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән «Кояш» дачасында әңгәмә // Кояш. 1913. № 188. 5 август.
27. Зәкәрия Садретдинов. Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән юлдашлыгым истәлекләре // Кояш. 1913. № 189. 6 август. б.2.
28. Зәкәрия Садретдинов. Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән юлдашлыгым истәлекләре // Кояш, 1913, № 190, 7 август, б.2.
29. Зәкәрия Садретдинов. Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән юлдашлыгым истәлекләре // Кояш. 1913. № 195. 15 август.
30. Зәкәрия Садретдинов. Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән юлдашлыгым истәлекләре // Кояш. 1913. № 196. 16 август.
31. Кәрим Сәед. Мәхмүд Әсад Әфәнде // Кояш. 1913. № 199. 25 август.
32. Мәхмүд Әсад әфәнде вә Русия мөселманнары // Кояш. 1913. № 217. 15 сентябрь.
33. Казан 16 сентябрь // Кояш. 1913. № 218. 16 сентябрь.
34. Дахили (эчке) хәбәрләр// Тәрҗеман. 1910. № 15. 9 апрель.
35. Мәхмүд Әсад әфәнде // Тәрҗеман. 1913. № 193. 3 сентябрь.
36. Безнең хакта ни диләр // Тәрҗеман. 1913. № 202. 13 сентябрь.
37. Исламчылык төркчелек // Тәрҗеман. 1913. № 213. 28 сентябрь.
38. Мәхмүд Әсад әфәнде Финляндиядә // Тәрҗеман. 1913. № 277. 17 декабрь.
39. Мәхмүд Әсад әфәнденең килеше // Йолдыз. 1913. № 1017. 4 август.
40. Мәхмүд Әсад әфәнденең килеше // Йолдыз. 1913. № 1018. 6 август.
41. Мәхмүд Әсад әфәнденең килеше // Йолдыз. 1913. № 1021. 13 август.
42. Мәхмүд Әсад әфәнденең фикере //Йолдыз. 1913. № 1038. 24 сентябрь.
43. Мәхмүд Әсад әфәнденең фикере // Йолдыз. 1913. № 1040. 29 сентябрь.
44. Фатих Кәрими. Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. 1913. № 1263. 31 июль.
45. Фатих Кәрими. Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. 1913. № 1264. 1 август.
46. Фатих Кәрими. Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. 1913. № 1265. 2 август.
47. Фатих Кәрими. Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. 1913. № 1266. 3 август.
48. Мәхмүд Әсад әфәнде Уфада // Вакыт. 1913. № 1267. 4 август.
49. Мәхмүд Әсад әфәнде Мәскәүдә// Вакыт. 1913. № 1273. 13 август.
50. Абдуллаһ әл-Мази. Мәхмүд Әсад әфәнде бин Әмин әл-Сәйдишәһри // Дин вә мәгыйшәт. 1913. № 31. август. 491-492 б.
51. Дин үзгәртү // Дин вә мәгыйшәт. 1913. № 32. август. 517-521 б.
52. Мәхмүд Әсад әфәнде яһут ислахат-ы диния // Дин вә мәгыйшәт. 1913. № 40. ноябрь. 633-634 б.
53. Мәхмүд Әсад әфәнде яһут ислахат-ы диния // Дин вә мәгыйшәт. 1913. № 42. ноябрь. 664-665 б.

**Әдәбият**

1. *Celal Nuri.* Şimal Hatıraları. İstanbul, 1330. 128 s.
2. *Харис Фәйзи.* Садретдин бәйгә хитаб (мөрәҗәгать). Өлфәт. 1906. №27. 26 июнь.
3. *Акчура Й.* Сириядән II. Вакыт. 1913. № 1183. 24 апрель.
4. *Devlet N.* Türkiye'ye Katkıda Bulunan Tatar-Başkurtlar // Türkiye Cumhuriyeti Devleti'nin Kuruluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri. Kayseri: Erciyes Üniversitesi, Türk Dünyası Araştırmaları Merkezi, 1996. 468 s.
5. Мәхмүд Әсад әфәнденең килеше // Йолдыз. 1913. № 1017. 4 август.
6. *Кәрим Сәид.* Мәхмүд Әсад әфәнде // Кояш. 1913. № 199. 25 август.
7. *Айдын М.* Хөсәен Хилми Паша // Türkiye Diyanet Vakfı İslam Ansiklopedisi, 18. İstanbul, 1998. 550 б.
8. *Эрдогду А.* Махмуд Эсад Сәйдишәһри // Türkiye Diyanet Vakfı İslam Ansiklopedisi, 37. İstanbul, 2009. 585 б.
9. Хилми Паша // Нур. 1910. № 189. 31 март.
10. *Мортазин Ф.* Хилми Паша Самарада // Вакыт. 1910. № 609. 27 апрель.
11. *Ибраһим Г.* Дәврә-и галәм Хөсәен Хилми Паша // Бәйанелхак.1910. № 618. 25 май.
12. Петербургта Хилми Паша хөрмәтенә мәҗлес. // Йолдыз. 1910. № 528. 15 апрель.
13. Хилми Пашаның «Новое время»ны зиярәте хакында // Йолдыз. 1910. № 539. 13 май.
14. *Акчура Й.* Якташларыма хатлар // Әхбар. 1908. № 13. 11 январь.
15. *Кәрими Г.* Хилми Паша Мәскәүдә // Вакыт. 1910. № 606. 17 апрель.
16. Хилми Паша Варшавада // Йолдыз. 1910. № 532. 27 апрель.
17. Хилми Паша Казанда // Йолдыз. 1910. № 529. 19 апрель.
18. Татарстан милли архивы. Фонд 1, дело 4, саклану берәмлеге 4240.
19. Хилми Паша Мәдрәсә-и Мөхәммәдиядә // Йолдыз. 1910. № 530. 21 апрель.
20. Хилми Паша Казанда // Вакыт. 1910. № 607. 22 апрель.
21. Хөсәен Хилми Паша Русиядә // Тәрҗеман. 1910. № 18. 30 апрель.
22. Татарстан Милли Архивы. Фонд 1, дело 4, саклау берәмлеге 5468.
23. Hakkımızda ne diyorlar // Tercüman. 1913. sayı 202. 13 Eylül.

24. *Әмирхан Ф.* Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән «Кояш» дачасында әңгәмә // Кояш. 1913. № 188. 5 август.
25. Мәхмүд Әсад әфәнде Финляндиядә // Тәрҗеман. 1913. № 277. 17 декабрь.
26. *Кәрими Ф.* Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. 1913. № 1266. 3 август.
27. *Абдуллаһ әл-Мази.* Мәхмүд Әсад Әфәнде бин Әмин әл-Сәйдишәһри // Дин вә мәгыйшәт. 1913. № 31. август.
28. Дин үзгәртү // Дин вә мәгыйшәт. 1913. № 32. август.
29. «Мир ислама» журналы вә Мәхмүд Әсад // Вакыт. 1913. № 1312. 4 октябрь.
30. Махмуд Эсад эфенди в России // Мир Ислама. 1913. № 7. С. 462-483.
31. Мәхмүд Әсад әфәнде Уфада // Вакыт. 1913. № 1267. 4 август.
32. *Садретдинов З.* Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән юлдашлыгым истәлекләре // Кояш. 1913. № 189. 6 август.
33. *Алиев Ә.* Мәхмүд Әсад әфәнде Мәскәүдә // Вакыт. 1913. № 1273. 13 август.
34. *Türkoğlu İ.* Musa Carullah Bigi'nin dört kitabının hikayesi // Türk Dünyası Tarih Dergisi. 1997. sayı 131. Kasım. S. 13-16.
35. *Садретдинов З.* Мәхмүд Әсад әфәнде хәзрәтләре белән юлдашлыгым истәлекләре // Кояш. 1913. № 190. 7 август.
36. Мәхмүд Әсад әфәнде вә Русия мөселманнары // Кояш. 1913. № 217. 15 сентябрь.
37. Matbuat-ı Osmaniye ve Mahmud Esad Efendi // Sabah. 1913. sayı 8611. Eylül.
38. Кояш, 1913, № 218, 16 сентябрь.
39. Безнең хакта ни диләр // Тәрҗеман. 1913. № 201. 12 сентябрь.
40. *Акчура Й.* Юк-бар // Вакыт. 1909. № 524. 26 сентябрь.
41. *Әсад М.* Тарих-и ислам, I. Том. Казан: Миллият матбагасы 1908. 190 б.; Тарих-и ислам, II. том, Казан: Миллият матбагасы 1908. 80 б.
42. Издиваҗ (өйләнешү) мәсьәләсенең фәлсәфәсе // Шура. 1911. № 1.
43. *Кәрими Ф.* Мәхмүд Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. 1913. № 1263. 31 июль.

---

# ПУТЕШЕСТВИЕ ХУСЕЙНА ХИЛЬМИ-ПАШИ И МАХМУДА АСАДА ЭФЕНДИ ПО ИДЕЛЬ-УРАЛУ

**Исмаил Тюркоглу**,
Университет искусств Мимара Синана,
Турция, 34427, г. Стамбул, Фындыклы,
turkogluismail@yahoo.de.

В статье описываются путешествия по России, в частности по Идель-Уралу, совершенные в начале XX века великим везиром (премьер-министром) Турции Хусейном Хильми-пашой и министром финансов Махмудом Асадом эфенди. В 1910 году в рамках восьмимесячной поездки по Европе Хильми-паша побывал, наряду с Москвой, Петербургом, Нижним Новгородом, и в Казани. В ходе путешествия он знакомится с духовной и культурной жизнью мусульман, что стало значительным событием для того времени: в истории Казани впервые состоялся прием Османского паши, который был принят со всеми почестями и уважением.

Во второй части статьи анализируется путешествие Махмуда Асада эфенди по Идель-Уралу. Дается обзор газетных публикаций того времени о данной поездке. Путешествия Хильми-паши и Махмуда Асада эфенди, с одной стороны, характеризуют взаимотношения между Турцией и Россией, с другой – указывают на усиление духовных, культурных, религиозных взаимосвязей между татарами и турками, укрепление нитей дружбы и родства между народами. В местной печати содержалась богатая информация не только об этих поездках, но и об известных людях. Все это позволяет читателям сформировать представление о культурной, духовной жизни татарского и турецкого народов того времени.

**Ключевые слова:** мусульмане России, регион Идель-Урал, национальное просвещение, школы-медресе, татарская интеллигенция, российско-османские государственные отношения.